

ХАЛИСӘ МӨДӘРРИСОВА

# Шәмәхә төн



Шигырьләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
М 97

**Мөдәррисова Халисә**

М 97 Шәмәхә төн: Шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 127 б.

Бу — Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар шагыйрәсенең Казанда чыккан беренче китабы. Аның шигырьләре самимилекләре, нечкә күңел белән язылган булулары белән үзләренә җәлеп итәләр.

ISBN 5-298-01289-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2003

«Безнең барлык — үзе бер вакыт...» Шулай яза шагыйрә үзенең бер шигырендә. Ә бит аның әле кабатланып килүче тагын шундый юллары да бар: «Вакытларны, вакытларны булмый туктатып...» Әйе, булмый. Әмма аның мизгелләрен җыр итә алган шагыйрь, шиксез, үзен бәхетле тоя.

Халисә Мөдәррисова атлы шагыйрәне инде утыз елдан артык вакыт беләм икән ләбаса! Миндә дә истәлекләр, шигъри хатирәләр калган ул еллардан. Җитмеш беренче елның язында без, әле үзебез дә яшь саналган шагыйрьләр — Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалим һәм мин Уфага, андагы университетның татар бүлеге оештырган шигърият — Тукай кичәсенә кунак итеп чакырылган идек. Кичә бик матур узды, күп дусларны күрдек (әлбәттә, андый кичәләрнең берсеннән дә калмый торган Әнгам агай Атнабай да бар иде анда!) һәм яңаларын да таптык. Студент шагыйрьләрдән Госман Садә һәм араларында иң яше — унсигез яшьлек Халисә белән шунда таныштык. Шигырьләрен дә укыды ул — үзен дә, язганнарын да ошаттык, Казанга күчеп килергә кыстадык. Бигрәк тә мин. Үземнең дә шулай күчү — Уфадан Казанга килү тәҗрибәм бар иде бит! Әмма Халисәгә Уфадагы остазлары Нажар Нәҗми, Әнгам Атнабайлар башкача киңәш бирде, ахры... бераз вакыттан соң Госман Садәбез Казанга күчеп килсә дә, Халисә килмәде, күчмәде. Үз туфрагында үсәргә тиешле шагыйрь сурәте җанлана иде шигырьләрендә — нәкъ яшел үләнгә сәйранга чыккан яшел бәбкә халәте...

«Тәрәзәмдә кояш байый, туар өчен яңасы» дип, яки яшьлеккә хас садә сөю өзгәләнүлә-

рендә: «Бирегез сөйгәнемне!» — дип таләп итеп, һәм шул ук ярына: «Шакымыйча килеп кердең, шакымыйча чыгып кит», — дип әйтергә дә көч табып, Халисәбез Уфадагы әдәби мохиттә, «Кызыл таң» исемле татарча газета каршындагы түгәрәктә үсте. Үзе дә университетның «Акчарлаклар» әдәби түгәрәген җитәкләде...

Бу очрашудан күңелдә бер якты тойгы калды һәм... Казанга чакырып та, килмәвенә үкенеч белдереп, шигырь язылды. («Бер чакыру калды Уфа өчен, бер кайтаваз кайтты Казанга...» дигән юллары да истә!) Әмма Халисәбез Казанга кунак булып еш килә торды — әүвәл студентлар ул чактагы яшь шагыйрьләр Зөлфәт, Роберт Миңнуллин, Шәмсия Җиһангирова, Фәннур Сафин, Марсель Галиевләр белән танышты, дуслашты. Шигырь укулардан гөрләп торган тулай тораектагы кичәләрдә мин дә булгаладым — яшьлеккә хас омтылышлар, әлбәттә, безгә дә йогынты ясагандыр... Кыскасы, багланышлар өзелмәде. Татарстан матбугатында да шигырьләрен бастырды Халисә... Инде университет тәмамлап, Башкортстанның Илеш, Нуриман, үзе үскән Иглин районнарында укытучы, хәтта мәктәп директоры булып эшләргә өлгерде. Тормышка чыкты, бер-бер артлы кыз һәм ул табып, инде гаиләсе белән күчеп, Нуриман районында эшли башлады — район советы секретаре булып эшләде ул. Хәзер дә шунда — район мәдәният бүлеген җитәкли. Кырыс, ирләрчә ныклык таләп иткән эш!

Һәм шул вазгыятьтә — шигырьләр язу, иҗат. Пародокс кебек...

Халисәнең беренче китабы Уфада 1982 елда чыкты — «Көмеш дага» исемле, башкортча басма. Икенчесе — «Җәй уртасы». Озак еллардан

соң — 1993 елда басылды. Аннары — 1995 тә — «Былтыргы көз»... Ә инде 1996 елда татарча «Балан» китабы дөнья күрде. Шулай ук Уфада. Бу чорда Халисә турында җитди мәкаләләр дә, җөмләдән Нажар ага Нәҗминең бик җылы, матур тәнкыйть язмасы басылды. Азак ул мәкалә бездә — «Казан утлары»нда да дөнья күрде. «Казан утлары» дигәннән, төрле елларда (әмма бүленеп торган чаклары да булды... Бу — Уфада яшәүче татар шагыйрьләренең гомум язмышы иде. Фәрит Габдерәхим, Рим Идиятуллин, Рәшит Гатауллин, Нәҗибә Әминева, Марис Нәзиров, Мөнир Вафин һәм башкаларныкы кебек, мөгаен...) Халисә безнең журнал сәхифәләрендә дә күренә килде. Әмма... минем карашка, Халисәне Казанга, әдәби-мәдәни җәмәгатьчелеккә таныткан нәрсә — әүвәл аның җырлары булды бугай: «Их, мине, кыюсызны», «Утырмадың атларыма» һәм, әлбәттә инде, «Балан» кебек популяр җырларны күз алдында тотып әйтүем. Һәм бу танышлык, якынлык һаман да дәвам итә.

Шигырьләре белән дә шул хәл. Китаплары басылгач, инде Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы да булгач (без аны, Уфадан Рим Идиятуллин, Рәшит Гатауллин белән өчесен бергә кабул итеп, котлаган идек!), шагыйрәнең Казанга килүләре тагын да тансыкка әйләнде. Һәр килгәнендә яңа шигырьләр уку белән мәҗлес-утырышлар булды, Тукай клубында да очрашу оештырдык, радиога шигырьләрен яздырып, тапшыруларда яңгыраттык, — кыскасы, Казан мохитендә дә үз кешегә әйләнде ул. Равил Фәйзуллин да, Зөлфәт, Мөдәррисләр дә, Роберт Миңнуллин, Зиннур Мансур, Марсель Галиевләр дә әйтә алыр иде моны. Шагыйрәләр — әйтик, Эльмира Шәрифуллина белән дуслыгы да үзе бер

шигырь кебек. Үзеннән яшьрәкләрне укып, мәсәлән, Луиза Янсуарның китабы белән танышкач, «Яңа бер шагыйрь ачтым!» — дип, телефоннан сөенеп шылтыратуы да матур фал иде аның!

Шигырьләр, очрашулардан хатирәләр, гомер, аккан вакыт... Алар турында Халисәнең бик матур шигырь юллары бар.

Һәр очрашу безгә бәйрәм булсын,
Тансык булсын дуслар ишеге.
Ә китүем һәрчак сагыш булсын,
Мәңгелеккә китү шикелле.

Гадилектә шул матурлык, шигърилек, дип катткат әйтәсе килә, мондый юлларга юлыккач. Ә алар Халисәдә күп, бик күп! Мисал китереп, күчереп язу өчен дә табак-табак кәгазь кирәк булыр иде. Ә барыбер мисалга китерәсе, сөенеч уртаклашасы килә. Башкаларга охшамаган, үзгә бер шигъри җан анда!

Мин — хатын-кыз, бары яратыгыз,
Минем вакыт — кыска таң кебек, —

ди ул җан, өзгәләнеп. Һәм үз кадерен, бәһасен дә белә Халисә:

Пәйгамбәр яры яшендә —
Минем иң пешкән чагым, —

дип яза шагыйрә, «Хисләрне тыймас чагым...», «Сөелеп туймас чагым» дип тә әйтергә онытмый. Илаһи Наз, аңлау көткән шагыйрә, хатын-кыз сурәте бу! Шуңа да аның бу бабта үзенә тугрылыгын раслаган «Үз юлымда һаман сөю яна, Пәйгамбәрләр тәкбир әйтерлек» дип язуы да сокландыра мине. Һәм минем күңел дөньяма авваздаш тоелган лирик героиняның «хисләр танта-

насы», — «әйтеп бетергесез хозурлыгы» да якын шул.

Син бар миндә — шуңа гомер көзем
Барлык язларыма торырлык (!).

Шушы юллары гына да Халисәнең төсләргә, сурәтләргә бай шигъри палитрасын, назикъ һәм горур уй-фикерләр тулы күңел дөньясын укучыга ачып бирәдер, шаять. Әйе, хатын-кыз җаны бай: анда мәхәббәт ашкындырган яшь кызлар хисе дә, «Көмеш дага»га лаек тол хатыннар акылы да, шуларга тиң сабыр урманнар да, барлык нәфис затларның күз яше дә юып бетерә алмас канлы Чечня яралары да, гомумән, бөтен ыгы-зыгысы белән бүгенге заман-дәвер, хәтта дөнья гаме дә сыйган. Әлеге атаклы «Балан» җырындагы «әкрен генә, баштан сыйпап эндәшүче» Әни һаман-һаман баласына киңәш бирә әле. Әйе, инде колын итеп күреп әйтә: «Офыкны куып тотмыйлар, җитәм дип чапма, тилем... Офыгыңның зәңгәр чиге — нәкъ басып торган җирең», — ди Әнкә. Ә Колын — мәңгегә ашкынучы җыр күңеле нишли?

Очкыннар чәчә тояк.
Ә офык — һаман ерак.

Безгә бик таныш халәтне, иҗади, шигъри яшәешнең нәкъ үзен ача, мөгаен, бу юллар! Һәм бу сурәтләр Халисә өчен бик табигый; алар — аның проза әсәрләрендә дә бар.

Әйе, менә бу китап та — әнә шундый шигъри асыл тоякның очкыннары, ташка бәреп тапкан утлары, мөгаен: әйдәгез, танышыгыз, укыгыз аны: ниһаять, Казанда да китабы чыга Халисә Мөдәррисованың. Шунысы да бар: Уфада ул Ха-

лисә Мөдәрисова булып, бер «р»ны югалтып йөргән иде. Ә мин аны ике «р» белән язам: татар әйтсә, каты итеп, чатнатып әйтә ул. Шагыйрә дә шулай.

Котлы булсын китабың, Халисә Мөдәррисова!

*Рәдиф Гаташ*
*21 гыйнвар, 2003*

# I

*«...Без мәңгегә җиргә килмәгәнбез,*
*Безнең барлык — үзе бер вакыт.*
*Бер-беребезнең кадеребезне белик,*
*Вакытларны гына, вакытларны гына,*
*Вакытларны булмый туктатып...»*



# Вакыт

Вакыт толымнарын урәм-сутәм,
Кыш, язларны көтәм һәрвакыт.
Агачларда — алтын, чәчтә — көмеш,
Кышларымны гына,
Язларымны гына,
Җәйләремне булмый туктатып.

Еллар ялына ябышып китим мәллә,
Учларымнан ага ком-вакыт,
Йөрәк җырым әле җырланмаган,
Елларымны гына,
Айларымны гына,
Көннәремне булмый туктатып.

Карашларың кагылып-кагылып китә,
Күзләремне яшерәм һәрвакыт.
Үкенермен әле: ник кыймадым?..
Сәгатьләрне генә,
Минутларны гына,
Секундларны булмый туктатып.

Без мәңгегә җиргә килмәгәнбез,
Безнең барлык үзе — бер вакыт.
Бер-беребезнең кадеребезне белик,
Вакытларны гына,
Вакытларны гына,
Вакытларны булмый туктатып.

# Ташлар җыям

Ташлар җыям, төсле ташлар...
Дөнья гүзәл, дөнья садә.
Тормыш кебек чал дулкыннар
Бер тына, бер ярга бәрә.

Дулкын чигә, юеш ташлар —
Берсе — якут, берсе — алмаз,
Йә зөбәрҗәт кебек яна,
Кем иелеп аны алмас!

Мин — әкият дөньясында:
Асылташ, дим, аяк аста.
Тик тамчылар кибәләр дә
Әйләнәләр чуерташка.

Үлә нурлар, сүнә төсләр,
Таш таш булып кала бирә,
Ә битараф чал дулкыннар
Яңа ташлар кага бирә.

Асылташ дип, чуерташка
Алданулар булды инде;
Бер балкысам, мең сүрелдем,
Күңел әрнеп тынды инде.

Учым тулы, кесәм тулы,
Җанда ята күпме ташлар...
Җыйдым үзем, бәрде кеше —
Яраланды җаннар, башлар.

Яуган ташлар авырттырып,
Күңелемне китеп килә,
Гомер үтә, шул ташларны
Санар вакыт җитеп килә.

Ташлар җыям... Тик дөньяга
Мин таш түгел, аш атармын.
Ә ташларны...
Күңелемә атканнарын,
Йөрәгемдә ятканнарын
Җырларымда балкытырмын.

## Минем халкым

Ераклардан, тарих төпкеленнән
Болгар — татар булып калыкты.
Хәтере — хак, намусы ак булыр
Сөембикәсе булган халыкның.

Төртенергә төртеп бастырса да,
Коръән уты җанын яктыртты.
Көнен буды, динен буалмады
Мәрҗание булган халыкның.

Кадерле бер асыл җәүһәр итеп,
Татар телен җиргә танытты.
Телен кисеп, аңын каплап булмый
Тукайлары булган халыкның.

Катламнардан яшел шытым булып,
Төрмә ташын тишеп калыкты.
Тоткын итеп, тезләндереп булмый
Мусалары булган халыкны.

Сүзен әйтер, миссиясен үтәр
Сокландырып олпат тарихны.
Чорлар йотмас, вакыт үтерәлмәс
Киләчәге булган халыкны.

# Әй гомерләр...

Тәү тамчылар җыр башласа,
Күзен ачса ак бөреләр,
Картәтием әйтер иде:
«Тагы да яз, әй гомерләр...»

Күкри күкләр, җәйгор төсе,
Дулкынлана мул игеннәр,
Күк чәчкәләр, күктә — тургай,
Күңелдә — җәй, әй гомерләр...

Покосларда печән кибә,
Хушлаша җәй, иңә көзләр.
«Киләсе җәй кемнәр булыр,
Кемнәр булмас, әй гомерләр...»

Аңлат, дисәм, картәтием,
Бу сүзләрнең серен миңа,
Әйтер иде: «Берчак аны
Ачып бирер үзе дөнья.

Гомерләрнең һәр мизгеле
Килә-китә, яна-сүнә,
Киткәннәр югалту булсын
Калганнарның һәммәсенә».

Язмышымның тик яз башы,
Күңелемдә — ак бөреләр.
Ләкин алтын яфрак ява
Картәтием каберенә.
Әй гомерләр...

* * *

*Нажар ага Нәҗмигә*

Әйтерсең лә безгә санамыйча,
Үлчәмичә гомер бирелгән.
Кадерен белми көннәр-сәйләннәрне
Коябыз без гомер җебеннән.

Мәшәкатьләр, ыгы-зыгы белән
Бу дөньяны кемнәр үзгәртә?!
Кемнәр килеп, кемнәр киткәннәрен
Битараф ай гына күзәтә.

Җандай дуслар белән бер сөйләшсәң,
Кайгыларың була көл-күмер.
Өлгермибез, «эшем кешеләре»,
Әйтерсең лә ике бу гомер.

Зәңгәр кичкә, бәсле иртәләргә
Сокланып та туймас вакытта,
Кадерен белеп сөяр иркәләрне
Күмәбез без арзан ваклыкка.

Чәчеләбез, түгеләбез һаман,
Күз төбенә сызыла җыерчык.
Сәйлән-көннәр гомер-җептән ага,
Мәңге тик ай — көләч кыерчык.

# *Көмеш дага*

Исемдә иске алачык,
Учакта күмер яна.
Алачыкта картәтием
Атларга дага кага.
Үзе сөйли: «Гел көмештән
Бар бәхет дагасы, — ди, —
Бик бәхетле кеше генә
Даганы табасы», — ди.
«Яу җиңеп агаңнар кайтыр,
Даганы тапсаң хәтта...»
Ә җиңгиләр сабан сөрә
Дагасыз арык атта.
Мин бер сабый, мин ышанам,
Эзләмимен яңасын,
Менә-менә табармын дип,
Эзлим бәхет дагасын.
Эзләсәм дә, табалмадым
Шушы көмеш даганы,
Тапмасам да, тик барыбер
Тынды сугыш яланы.
Югалган көмеш дагадай,
Агайларым кайтмады.
Еллар үтә, бүгенгәчә
Исән агам хатлары.
Сынык дага кебек ятим
Тугры җиңгәм антлары.
Балачагым күптән үтте,
Инде артта калганда,
Ләкин мин һаман ышанам
Шушы матур ялганга.
Миңа кирәкми даганың
Алтыны, көмеше дә,
Төшерә төште барыбер
Үземнең өлешемә.

Тик һаман да дага эзләп,
Юллардан үтәм менә.
Тапсам — элеп китәр идем
Җиңгиләр читәненә.

## Тоз һәм шырпы

Җиде төндә урман шырлыгында
Калганым бар минем адашып,
Юк, куркудан түгел, ялгызлыктан
Мең җанварның тоеп карашын.

Каңгыраган бар ялгыз юл табалмый,
Күзне каплаганда өермә,
Юлыккан бар дәрвиш кебек ялгыз,
Өметкә тиң аучы өенә.

Шушы өйдә җанда җылы туа,
Әйтерсең лә язгы яшь курпы.
Иң кыйммәтле хәзинәдән кыйммәт —
Киштәсендә ята тоз-шырпы.

Җаннарыма салкын үтеп кергәч,
Инде бетте дигәч өметем,
Калтыранган бармакларым белән
Бер шырпыдан учак терелттем.

Төнге учак, мәңгелеккә өндәү,
Мин Җиһанда — тере төерчек.
Йөрәгемә шифа булып ятты
Күз яшедәй тозлы кыерчык.

Гомерем үтеп, алыш-биреш бетеп,
Фани дөнья миннән узса да,
Кешеләргә калдыралсам иде
Тоз һәм шырпы гына булса да.

# Танклар китә Чечняга

Чечняга китә танклар —
Кавказ төбәкләренә.
Ләгънәт, каргышлар урала
Состав көпчәкләренә.

Ыргак салып туктатыйммы
Каеш аелларына?
Ак кәфен килеп урала
«Урыс» каеннарына.

Вәхшилеккә куа Рәсәй
Кемнең бер бөртекләрен,
Күршене керөп кырырга
Өйрәтә егетләрен.

Иртәгә шулай танклар
Ташланса минем илгә?
Ышанып балам бишеген
Эләм аламмы өйгә?!

Кайда сез, безнең чын ирләр?
Сәясәт «акыл» җыя.
Котырган бүренең тешен
Сәясәт түгел,
Ныклы мускуллар гына коя.

Ирләр, ирләр, кайдасыз сез,
Илләр утта яна бит.
Чечен улы, урыс улы —
Ул барыбер — бала бит.

Ак яулык тотып йөгерәм
Мин состав алларына...
Танклар китә Чечняга,
Нинди ата баласының
Гөнаһсыз җаннарына?

## Ялгыз кабер

Зиярат булган, асфальт юл үтә,
Ялгыз кабер Сырыш елгада,
Агыла кеше, агыла машина,
Ашыга галәм фани дөньяда.

Нәрсә өчен килдең, кем идең,
Кая киттең? Юкка җан кыйнау.
Ялгыз кабер — өнсез мәңгелек,
Җаваплары булмас бер сорау.

Үтәрмен бит мин дә дөньядан,
Яңгыр юар кабер ташымны,
Их, шул чакта җавап биралсам,
Ташларыма куйгач башыңны...

Ялгыз кабер ташын җил кайрый,
Вакыт тора комнан, күмердән,
Бу дөньяның барлык соравы,
Бар җавабы шунда күмелгән.

## Язгы төш

Язда шундый төшләр күрәм:
Сулар тирән, чайкала,
Тотыгыз, тот кош баласын,
Ага инде, чак кала...

Уянам да уйга калам —
Мартның соңгы бураны,
Ераклардан кайткан кошлар
Кайда корырояны?

Яз дип кайткансыздыр да бит,
Кыш әле, кыш бу якта.
Ташкын әле кайчан китәр,
Әле язлар еракта.

Чакрым-чакрым җилләр йотып,
Язларга кайткансыздыр,
Чыдармы соң соңгы җилгә
Талчыккан канатыгыз?

Усал җилләр каерса да,
Өметнең канатларын,
Кошлар да бит минем кебек,
Беләләр ташу барын.

Канатларны ныгытырмын
Җилләргә ятып кына,
Яралардан арынырга
Бирегез вакыт кына.

* * *

Бөтенләйгә түгел, бер сәгатькә
Мин дусларсыз калдым,
Бөтенләйгә түгел, бер сәгатькә
Мин дошмансыз калдым.

Бүлмә тып-тын, ә тәрәздә тик — төн,
Сәгать вакыт саный.
«Ялгыз калдың, ялгыз калдың», — диеп
Әйтерсең лә яный.

Мин бу төннең йолдызларын күрмим,
Аен күрмим аның,
Болытларын һәм утларын күрмим,
Таңын көтмим аның.

Иң яман һәм иң куркыныч
Бер бушлыкта йөзәм,
Яхшылык һәм явызлык та сизмим,
Мин ялгызлык сизәм.

Битарафлык, шатлану юк,
Күз яше дә коймыйм.
Мин үземне бу дөньяга
Кирәк итеп тоймыйм.

Бер сәгатьнең минутларын санап,
Дошманымны көтәм,
Һәр минутның секундларын санап,
Дусларымны көтәм.

## Туган җир

И Туган җир!
Син газизсең миңа.
Мин газизме сиңа бу дөньяда?
Бөреләрнең шартлап ярылуы,
Дулкыннарның ярга кагылуы
Җавап бирә кебек: «Газиз бала...»

Газиз миңа синең бар барлыгың,
Күңелеңдәй дәрья киңлекләрең,
Йорт-җиремдә — якты учаккынам,
Җан түнгәндә — ярым, кочаккынаң —
Ялгызымны озак тилмертмәдең.

И Туган җир! Син газизсең миңа,
Арып беткәч арзан ваклыклардан,
Буыннарда яңа куәт арта,
Тынгысыз җан йолдызларга тарта
Сулышыңа ныклап колак салсам.

И Туган җир! Син газизсең миңа,
Күзәтәсең минем язмышымны,
Авыр чакта — миһербанлы ана,
Ә ялгышсам — гүя олпат ата,
Төзәтәсең минем ялгышымны.

И Туган җир! Син газизсең миңа,
Сүзләр бармы әйтеп аңлатырлык?
Кабатланмас балам елмаюы,
Сөйгәнемнең җылы күз салуы,
Газизләрдән газиз синең барлык.

И Туган җир! Мин газизме сиңа?
Газиз булсам, уйда йөртерсең син,
Көмеш тамчы булып, яисә кар,
Мин киткәндә газиз бу дөньядан
Моңсу гына яшең сөртерсең бер.

* * *

Тол хатындай моңсу ак болытлар,
Шәфәкъларда — ялкын-яралар.
Кошлар китә, ә агачлар җирдә
Сары шәлен болгап калалар.

Табигатьнең соңгы күкрәве бу,
Хушлашуы бүген үзара.
Кан саркыган яңа яра кебек,
Куаклыкта балан кызара.

Язмыш кебек үрелеп-үрелеп үскән,
Тәлгәшләре тора тын гына.
Ак болытлар кебек тол хатыннар
Җырлый-җырлый колмак сындыра:

«Кайда икән, кайда яз айлары,
Кәккүк көткән чаклар үз парын.
Чәчкәйләрен ярым җилгә чәчеп,
Иярләгән чаклар тулпарын».

Кинәт җырны бүлеп, җир тутырып
(Яңгырап, чынлап китте буш тынлык),
Бар дөньяны сихри моңга күмде
Бөре кебек кенә бер кошчык.

Көзләр түгел, язлар кайтты җиргә,
Күкрәүләрне күмде бу йөрәк,
Әйтерсең лә яшәү матурлыгын
Исбат итә бүген табигать.

Яшәр әле, яшьнәр яз айлары,
Кәккүк чакырыр тагын үз парын,
Бөреләнер өчен яфрак коя
Тол хатындай сабыр урманым.

## Моңлы карт

Картәти музыкант түгел,
Җырчы түгел табында.
Ә шулай да «моңлы карт» дип
Йөретәләр авылда.

Җыр төсле бабам хезмәте,
Әкияткә тиң дөньясы.
Шагыйрь дә, рәссам да түгел —
Гади балта остасы.

Кызлар иңендә чайкалган
Көянтәсе, чиләге,

Ялкылдап һәм янып тора
Өй кәрнизе бизәге.

Бабам күңеле кебек киң
Капкада сыр-бөдрәләр,
Кояшка табан ачыла
Ул ясаган тәрәзләр.

Челтәрләнгән, бизәкләнгән,
Аерым кот табылган,
Авылның һәр йорты аның
Кулы белән салынган.

Аның моңы торып калган
Өстәлдә һәм ишектә.
Сабый тәү кат дөнья күрә
Ул ясаган бишектә.

Картәтинең кордашлары
Хәтта дөнья куйганда,
Васыять итеп ясатканнар
Каберләргә койма да.

Картәти юк инде күптән,
Ләкин халык теләндә —
Гади тугел, «моңлы карт» дип
Йөретәләр бүген дә.

Үзенә ул күп алмаган:
Каберендә үзе койган
Айлы сары чардуган,
Ә кешеләр тормышына
Җыр-моң бирел калдырган.

# Карт солдат

Ярты төн. Авыр болытлар
Җиргә елышып ага.
Юеш шинель чабуыдай,
Тыш капканы җил кага.

Дөнья тыныч, илләр имин,
Хәвефсез авыл төне.
Тик яңгырга колак салып,
Йоклый алмый бер кеше.

Тәрәзгә чиртеп бу яңгыр,
Әйтерсең хәл сораша.
Шыгыр-шыгыр, шыгыр-шыгыр —
Протез ыңгыраша.

Анын улы — чик сагында,
Илнең ныклы терәге.
Улы белән бергә сакта
Карт солдатның йөрәге.

Яңгыр ява, ничә еллар
Җир ярасын су юа.
Күк йөзен хәтер шикелле
Яшеннәр ярып куя.

Хәтер ярасы ябылмый,
Анын бит юк ишеге.
Акрын гына тибрәп китә
Оныгының бишеге.

Карт солдат әзер бүгеннән
Куярга илгә иңен.
Тамчылар бии урамда,
Дөньялар тора имин.

Тышта — яңгыр. Оныгының
Тыныч йокысын саклап,
Туган җиренә, иленә
Терәк үстерә солдат.

## Гомер

— Түбәтәең кысып тотып,
Нәрсә күзлисең, бабай?
— Яңа гына очып үтте
Балачак — шаян малай.
— Колагыңа кулың куеп,
Нәрсә тыңлыйсың, бабай?
— Яңа гына, сөю, диеп,
Былбыл өздерде шулай.
— Күз өстенә кулың куеп,
Нәрсә карыйсың, бабай?
Яңа гына үткән иде,
Яшьлегем — дәртле агай.
— Сукмагыңа күзең текәп,
Ни эзлисең, бабакай?
— Күңел тыныч, онык үсә,
Газиз җирдән мәңгелеккә
«Йорт» сайлыймын, балакай.

* * *

Юлсыз җирдән сукмак ярсаң,
Хәл алырга туктап калсаң,
Кимсенмә ут сорарга.
Авыр булса, шул кешеләр
Иңенә кулын салырлар,
Урын бир ул кулларга.

Дусларың әгәр ялгышып,
Рәнжетсә сине нахакка,
Тырыш син үткәрергә,
Авыр булса да, гафу ит,
Чөнки шул ук дуслар килә
Газабың күтәрергә.

Дошманың мактап сүз әйтсә,
Каршыңда елмайса, көлсә,
Ышанма, гафу итмә.
Дошманыңа кайгы килсә,
Вак җан булма, син шатланма,
Үч белән сату итмә.

Егылса синең янәштә
Һәм ярдәм сораса синнән,
Су эчер учларыңнан.
Ләкин үзең беркайчан да,
Егылсаң да, бер тамчы су
Сорама дошманыңнан.

## Җәяүле буран

*Биатаем Х.Янгиров истәлегенә*

Басу аръягында атлы
Җәяүле буран яра,
Толып якасын күтәреп,
Офыкка кереп бара.

Яшьлекнең алсу еллары
Окопта янган чакта,
Дошман алга, безнекеләр
Аркага аткан чакта.

Шушындый җәяүле буран
Булды өй дә, җаный да,
Хәзер менә йөзне капшый
Танымый да, таный да...

Чор үзгәрде, гавам — шул ук,
Бары башкарак тамга.
Алга да, артка да түгел,
Терәп аталар җанга.

Яшәү — мизгел, дөнья — фани,
Җилгә туза табышлар,
Буранда адашып кала
Ваклыклар, ышанычлар.

Гомер буе шушы буран
Озатты. Тотам калмый.
Бер дус була, берчә дошман,
Бер юата, бер алдый,
Тик барыбер ул — хәрәкәт,
Ул — омтылыш, ул — армый!

Бер җыр җырлап, бер шом салып,
Бер көч бирә, бер тыя,
Шуңа микән бу дөньяда
Яшәүләрдән кем туя?!

Юл башында җайдак — онык
Җилләргә йөзен куя.

# Алмаз

Грибоедовны үтергән өчен,
Шаһ алмазы белән түләнә.
Шаһ алмазы. Күпме сокланулы,
Көнләшүле караш астында
Горур ялтырап, үз бәясен белеп,
Янып торган шаһлар таҗында.

Күпме куллар аңа үрелмәгән,
Комсыз күзләр аңа бакмаган,
Ә ул һаман, горур чибәр төсле,
Үз бәясен үзе саклаган.

Таш диварлар, козгын җан патшалар
Һәм аларның кара големе...
Ялкын төсле таңда шагыйрь каны,
Шаһ алмазы — шагыйрь гомере.

Гомер өчен бәя — таш алмаз да
Бүлешалмас патша шатлыгын.
Бу горур таш, горурлыгын җуеп,
Елагандыр онытып ташлыгын.

Шул чагында ул да теләгәндер
Югалырга, мәңге тынарга,
Кешелекнең мәсхәрәсе түгел,
Гап-гади бер чуер булырга.

Ул кайчандыр битараф таш булган —
Шаһ таҗының гүзәл бизәге.
Бүген витринада яна алмаз,
Әйтерсең лә сак кулларга салган,
Мәңге тере шагыйрь йөрәге.

# Метеор монологы

Мәңгелектән мин бары бер метеор,
Аптыратып, бәлки, күпләрне,
Миллион еллар чиксез бу җиһаннан
Эзләп килдем сезнең күкләрне.

Салкын галактика куенында
Яралсам да бөртек таш булып,
Тарту көчен җиңеп күп кояшның,
Шушы күккә килдем ашкынып.

Урау-урау озын юлларымда
Юл яктыртты бары бер кояш.
Мәңгелекнең үзен җиңеп килдем,
Гел чакырды мине шушы яз.

Мин төш күрдем салкын бишегемдә:
Мәк яланын, яңгыр тамчысын.
Җил тавышын, чишмә чылтыравын,
Күкне телгән яшен камчысын.

Күңелендә йолдыз йөретүче
Хыялларын тойдым кешенең.
Кайнар йөрәк эзләп сезгә килдем,
Зинданнарның ватып ишеген.

Мәңгелектән мин бары бер метеор,
Юк, ул гаҗәп булмас күпләргә:
Мәңгелектән килдем бер секундка,
Яшьнәр өчен шушы күкләрдә.

## Язылмыйча калган шигырь турында

Авыр сөеп сөелмәве —
Сынган кебек канатлар.
Сөеп тә, сөймим, дип әйтү
Йөз кат авыр газаптан.

Авыр, елап күңел түгү,
Күз яше — әйтерсең ут.
Авыррак, теләгәндә
Елап булмаган минут.

Авыр, иң кирәкле сүзне
Сыйдыралмаса антлар.
Авыррак, сүз әйтеп тә
Аңлаталмаган чаклар.

Тик мең авыр җыр тумыйча,
Сүнсә бер балкыш кебек,
Кысыр болыт, ялкынсыз ут,
Канатсыз аккош кебек.

## Шагыйрь

Шагыйрь намусы — заман намусы ул,
Намуссызның илдә аты юк.
Шагыйрьләрдә иман бары бирәү,
Вакланырга аның хакы юк.

Бер кер кунса шагыйрь иманына,
Ярдәм итмәс хаҗга китүләр:
Шаян көчек кебек ялгыш өргәч,
Ил алдында тәүбә итүләр.

Муса рухын еллар кумә алмый,
Капласа да тәнен тар зиндан.
Лоркаларда иман бирәү булган,
Нерудада булган бер иман.

Йөрәк белән, күңел белән тоеп,
Шагыйрь аңлый кара һәм акны.
Кеше ялгышала, ә шагыйрьнең?..
Ялгышырга аның юк хакы.

## Кызыма

Урамда — март. Соңгы буран бурый,
Яз булмас та кебек быелга.
Ак касәдә гөл орлыгы йоклый,
Йоклый кыз күңеле, бар дөнья.

Быел шытып гөл буласы орлык,
Ниләр керә синең төшләргә?
Язгы кояш нуры, җәйге җилләр,
Кырау үбеп үтәр көз мәллә?

Гел орлыгы кебек яшь кызыма
Күп нәрсә сер, яңа, яшерен,
Уянасын белми, язлар көтми
Һәм уйламый кырау төшәрен.

Гомер язы якын, белми, кызкай,
Ак касәдә чәчкә орлыгы,
Урамда март, дөнья төшләр күрә,
Җирдә әле кышлар тынлыгы.

Тик яз якын инде...

* * *

Йоклый улым — бәләкәчем,
Арыган көлеп, елап,
Йоклый төшләр күрә-күрә,
Эшләп арыган сыман.

Йоклый, әйтерсең ишетми
Машина гөрелдәвен,
Урамдагы магнитофонны,
Яшьләрнең көлүләрен.

Күктә самолет гүләве —
Тәрәзләр чыңлап китә,
Күршедә иргә хатыны
Нәрсәдер исбат итә.

Йоклый кашларын җимереп,
Заман тавышы таныш,
Бакча аша тугайлыкта
Җилферди җикән камыш.

Кинәт улым күзен ачты,
Аптырап колак салды:
Уятты заман баласын
Тугайда утлап йөрегән
Ялгыз ат кыңгыравы.

* * *

Табигатьнең серле бу хәтере:
Сабый гына кызым, кызчыгым,
Машина һәм курчак бирсәң аңа,
Сайлап ала кулдан курчагын.

Сөйләшә дә белми әле үзе,
Орчык буе, ләкин аңлата:
Күкрәгенә кысып, тибрәлдереп,
Нидер көйләп курчак йоклата:
«Әлли-бәлли-бәлли-бәү».

Тәүге учакларның җылысында
Бәләкәчен назлап йоклаткан
Тәүге ана җыры үзгәрешсез
Килеп җиткән безгә моң саклап:
«Әлли-бәлли-бәлли-бәү».

Шул көйләрдә минем ана назы,
Ә аңа соң күчкән кемнәрдән?
Тарихларның төпкеленнән килгән,
Чыра яктысыннан, шәмнәрдән.

Минем күңелне дә били ул җыр,
Иң тәүге моң җанны уяткан.
Күкрәгемә кысып сабыемны
Бишек җыры көйләп йоклатам:
«Әлли-бәлли-бәлли-бәү».

Сабый кызым бишек көе көйли,
Тукта, вакыт, сабыр бул, әйдә,
Буыннарны буыннарга ялгар,
Бүгенгене киләчәккә илтер
Гап-гади җыр тыңла бермәлгә.

И кешелек, дөнья бишеккәе,
Иминлеге ана моңында,
Көчең синең бомбаларда түгел,
Хатын-кызда, бишек җырында:
«Әлли-бәлли-бәлли-бәү».

* * *

Нуриманым — җантөягем,
Кулләрендә — синең ямең,
Күкрәгендә — урманнарың,
Иделендә — тамыр каның.
Тыйнак, ихлас һәм кунакчыл
Кешеләрдә — җаның, даның,
Җантөягем — Нуриманым.

## Баланнар

Көзге урман. Сары ялан...
Коела кыңгыраулар.
Мәк гөледәй кызыл балан —
Каерып сындыралар.

Сабый күңле дертләп китә:
«Әни, ник сындыралар?
Баланнар бит коелмыйлар —
Коела кыңгыраулар...
Кыңгырау сындырсыннар...»

Акрын гына баштан сыйпап
Җаваплый миңа анам:
«Өлгергән инде балан,
Өзәргә кирәк, балам.
Авыр чаклар бик күп булыр —
Түзәргә кирәк, балам.

Буш хыяллар коела ул,
Аларны сындырмаслар,
Балан төсле күңел була,
Аларны тындырмаслар...»

Еллар үтте. Менә тагын
Кыраулар төшкән заман,
Өлгергән инде балан...
Кайчандыр коелган кебек,
Коела кыңгыраулар,
Йөрәк төсле кызыл балан —
Каерып сындыралар.

Колакта чыңлый һаман,
Пышылдый кебек анам:
«Өлгергән инде балан,
Өзәргә кирәк, балам,
Авыр чаклар бик күп булыр —
Түзәргә кирәк, балам».

Баланны өзәләр бит,
Җепләргә тезәләр бит.
Аунап елар чаклар була —
Йөрәкне өзәләр бит,
Барыбер түзәләр бит!

# Соңгы аваз

Бала-чага бүген чыр-чу килә,
Авыл өсте тора яңгырап:
«Әй сөенче, урман суы төшкән,
Урман суы төшкән яңарак».

Ә аннан соң торып йөгерәләр
Узыша-узыша ташу карарга.
Ах күңелем, кинәт шашып китте,
Иярәсем килде аларга.

Иярәсем килде, йөгерәсем,
Яланаяк таныш сукмактан.
«Юк, балалар сине үз итмәсләр», —
Шул уй булды мине туктаткан.

Боз өстенә учак яга идек,
Тик башкалар быел кабызган.
Кайсы язның икән зәңгәр бозы
Балачакны алып агызган?

Ярларыннан бозлар бер кузгалса,
Ярты юлда туктап туңармы?
Тиңдәшләр дә тормыш агымы белән
Борылмага кереп югалды.

Китәр идем эзләп үткәннәрне
Табар булсам әгәр агымнан.
Йөрим ялгыз, яңгырап ишетелә
Шат тавышлар елга ягыннан:

«Урман суы төшкән, урман суы...»
Таныш тавыш бала чагымнан —
Соңгы аваз бала чагымнан.

# Давыл

Әйтерсең лә яңа гына
Болын ярып казлар үткән,
Бу яланга ак мамыктай,
Тузганаклар сибелеп киткән.
Тузганаклар, тузганаклар...
Ап-ак алар, өмет кебек.
Чал болытлар баш очында,
Тузганаклар — ап-ак күбек.
Гүя басу капкасына
Яудан кайтып кергәннәрен
Каршыларга чыккан алар
Ак күлмәктән, сөйгәннәрен.
Шулчак кинәт давыл чыкты,
Агачларны иеп, бөгеп,
Яшь кәләшнең туй фатасын
Алып аткан явыз кебек.
Кара хәбәр кебек давыл...
Бөгелеп төште тузганаклар.
Давыл үтте, ә яланда,
Тол хатындай, кара көеп
Торып калды тик сабаклар.

* * *

Яшел үлән кебек яшел бәбкә
Тәү кат барлап йөри дөньяны,
Бөтен нәрсә сокландыра аны:
Үлән җыры, чишмә чыңлавы.

Тилгәннәрнең кара күләгәсе
Шом салалмый әле күңелгә.
Уйлый сабый, җиргә килгән икән,
Ул яшәргә тиеш мәңгегә.

Бәләкәй генә тәпиләре белән
Атлап керәп бара тугайга,
Яшел үлән кебек яшел бәбкә,
Ул ышанып карый дөньяга.

## Хушлашу

Әй яшьлек безне дә калдырды,
Хушлашып та хәтта тормады,
Әйтерсең шау-шулы зур кала
Борылма артында югалды.

Ул илдән теләкләр, хыяллар
Дөньяны гөл итәр омтылыш,
Озатып киләләр юлларга,
Күңелдә китәләр җыр килеш.

Узса да бу еллар шундый тиз,
Узгандай ашыгыч составлар,
Барыбер йөрәктә яшьлектән
Ал җилкән күтәргән кораб бар.

Гомернең яшьлек дип аталган
Чоры — тик ул очыш күпере.
Күңелдә калсын тик ак ядкәр,
Купеда онытып калдырган
Яшь кызның яулыгы шикелле.

## Йөрәк кылым

Чит җирләрнең көзе алтын түгел,
Чит җирләрнең көзе — сары сагыш.
Кошлар оча, канатларда китә
Туган якка булган минем алкыш.

Кошлар, кошлар, калдырмагыз мине,
Сезнең тавыш миңа күптән таныш.
Мин канатсыз монда, чит җирләрдә,
Көзләре бит алтын түгел — сагыш.

Чит җирләрнең көзе ялкын түгел,
Тәне җылы аның — җаны салкын.
Үз илемдә хәзер якты яздыр,
Тал бөресе көмеш керфек ачар.

Кошлар, кошлар, калдырмагыз мине,
Ияртегез мине үз илемә.
Язы көмеш, көзе алтын булган,
Йөрәк кылым булган Агыйделгә.

# Чәчкә көне

Гөлләр төш күрә түтәлдә:
Болыт назын, кояш нурын,
Күбәләкнең иреннәрен,
Таң җиленең иркә җырын.

Саксыз куллар кагылалар,
Гөлләр дертләп күзен ача.
Шулай иртә йөри кеме?
Ак таҗлардан чыклар кача.

Көмеш җепкә чылбырланган,
Әйтерсең лә кол базары.
Җинаятьче кебек бәйдә,
Кемнәр аңлар гөлләр зарын?!

Яраланган аккош кебек,
Ак ромашка башын игән,
Кызыл роза чәчәгенең
Бөтерелеп таҗы көйгән.

Чибәр ханым чәчкә сайлый —
Кочагында — йөге белән.
Үстәл бизәр өзелгән гөл
Ике көнлек гомере белән.

Ниләр тоеп-кичергәнен
Аңлаталмый гөлләр теле.
Вазаларда, кибетләрдә, кочакларда,
Тузаннарда чәчкә сула.
Бүген монда чәчкә көне,
Чәчкә көне.

# I

«...Йолдыз димә, кояш димә,
Алтын да көмеш димә,
Ничек бармын, шулай ярат,
Бары шул килеш кенә...»



## Сагындым сөйгәнемне

Беләмикән еракларда
Ялгызым йөргәнемне?
Дөньяларның кызыгы юк —
Сагындым сөйгәнемне.

Беләмикән аның өчен
Янганны, көйгәнемне?
Тормыштан кызык тапмыймын —
Сагындым сөйгәнемне.

Беләмикән юлларына
Көн саен килгәнемне?
Түзәр хәлләрем калмады —
Сагындым сөйгәнемне.

Кискәләп өзгәләмәгез
Әрнегән йөрәгемне.
Гомерләрем дә жәл түгел —
Бирегез сөйгәнемне.

* * *

Болытлар тулышып тора,
Анда да шулай микән?
Койма яңгырлар яуганда,
Тәрәзләр елый микән?

Агачларны җилләр бөгә,
Анда да шулай микән?
Миләшләр яфрак койганда,
Ул мине уйлый микән?

Бәлки, анда аяз күктер,
Тәрәзләр еламыйдыр,
Миләшләр кан-яшь койса да,
Ул мине уйламыйдыр.

## Төнге урам

Бәхетемне күпсенде дә
Урлады төнге урам.
Урамда калды сары көз,
Күңелдә — кара буран.

Ул ятныкы була алмый,
Ул минем өчен туган,
Урлама син аны миннән,
Калдырчы, төнге урам.

Сизмисеңмени, күңелләр
Мәхәббәт белән тулган,
Араларга йолдыз төшәп,
Кавыштыр безне, урам.

Бәхетемне күпсенде дә
Урлады төнге урам.
Әйтелмәгән серләр калды,
Күңелдә — кара буран,
Җавап бирми таш урам.

* * *

Көзге яфрак — ялгыз аккош
Тирбәлә дулкыннарда.
Өзелеп сөйгән ярларым бар,
Туктар ярларым кайда?
Ишетелеп кала аһәң:
«Бу бит мин, әйдә йөгер...»
Тик ярларда — ят чәчәкләр —
Минем чәчәкләр түгел.
Ерак кала, ераклашам,
Офыкта кала назым,
Көз көен чиртеп, һаман да
Сагая бара сазым.
Көзге яфрак, ялгыз аккош
Тирбәлә дулкыннарда,
Кала йөрәк, кала ялгыз
Әрнергә, сулкылдарга.

* * *

Хыялларым, омтылышлар
Баш кинәрлек юлсызмы?
Сайлап алдым биектәге
Зәп-зәңгәр бер йолдызны.

Ашалмаслык хыял, диеп
Әйтмәгезче, дусларым,
Йолдызымны югалтсам соң
Берьялгызым нишләрмен?

Ераклардан яңгырап килгән
Хыялымның җыры син,
Ерак булсын, барыбер тоям
Йолдызымның җылысын.

## Кем син?

Кем булдың син?
Урак йолдыз кебек,
Күрендең дә миңа бер кичтә.
Күңелем күген ялтлап яктырттың да,
Җылы бирми җанга, юк, һич тә, —
Югалдың син. Әллә ялгыш кына
Сирпеп үтте мине карашың,
Күзләреңнән күзем алалмадым,
Хыялларга кереп адаштым.

Син бит миңа якты йолдыз булып,
Яңа йолдыз булып күрендең...
...Йолдызларга кемнең буе җиткән,
Мин, хыялый, шуңа үрелдем.

## Аяз яңгыр

Сәйлән-сәйлән яңгыр ява
Үләннәргә чык булып,
Гүя энҗеләр коела
Келәмнәргә чук булып.

Яңгыр болытлары аша
Әнә кояш күренде,
Нурларыннан зәңгәр күктә
Салды алтын күперен.

Салават күпере аша,
Яңгыр аша килдең син,
Утлы карашларың белән
Күңелемә кердең син.

Җәйге яңгыр үтеп китте —
Күңелемә и рәхәт!
Үтмәсен, һәрчак яшәсен
Йөрәкләрдә мәхәббәт.

* * *

Декабрьдә яңгыр явып үтте —
Яз килдеме?
Кыш чиктеме артка бер адым?
Ә син, кызый, тиле көнгә карап:
«Сөю килде», — диеп юрадың.

Бу адашкан яңгыр,
Ә артыннан
Килә кышның зәһәр бураны.
Ашыктырма язны, көрт басмасын
Күңелеңнең яшел урамын.

Кышкы яңгыр җылы яңгыр түгел,
Яз бирүе аның — икеле.
Юк, булмасын, сеңлем, синең сөю
Кышын яуган яңгыр шикелле.

* * *

Йөгерә-атлый миннән ераклаштың,
Кояшымның чите кителде,
Мин югалттым сине көтмәгәндә,
Көтмәгәндә тапкан шикелле.

Үпкәләмим үтеп киткән өчен,
«Ташламам», — дип, вәгъдә бирмәдең,
Моңа чаклы хәтта беркайчан да,
Юк, булмады сине күргәнем.

Тик бик күптән сине көткәнемне
Мин йөрәгем белән аңладым,
Ничек кенә сине сагынсам да,
Минем янда туктап калмадың.

Син бик якын миңа, ә мин сиңа
Очраклы бер юлчы, чит кеше.
Артларыңнан куып җитәр идем,
Тик ярамый,
Сине көтә анда икенче,
Ә мин сиңа — башка, чит кеше!

* * *

Аерылыштык...
Арабызга ятты
Олы юлның соры тузаны.
Уйлый идем, алып китәрсең, дип,
Үзең белән барлык узганны.

Юк икән шул, күпме хатирәләр
Кайта төштә, кайта өнемдә,
Ишеткәндәй булам синең җырны
Бәллүр төсле август төнендә.

«Оныт аны», — дип күпме тапкыр
Ярсу йөрәгемә тукыдым,
Үзем сиңа атап җырлар яздым,
Үзем күңелемнән укыдым.

Онытыйм дип инде әйтмим дә мин,
Сине сагынам, синең җырларны.
Хыялым бер: язмыш мәңгелеккә
Кавыштырсын иде юлларны.

# Үпкәләтмә

Бар барлыгым белән мин синеке,
Яши алмам синсез.
Киткән чакта үпкәләтеп китсәң,
Кайгыларым — тиңсез.

Киләм, диеп килми калсаң,
Сагышлана таңым,
Күзләреңдә мин чагылсам,
Гафу итәм тагын.

Ятка китмә, читкә типмә,
Еракламашма шулай,
Тын урамда — төн шомлыгы,
Күңел әрни, елый.

Синсез генә газап чигү
Авыр, авыр миңа.
Күкрәгеңә кысып сөй дә
Кайгыларны чиклә,
Киткән чакта беркайчан да
Үпкәләтеп китмә.

* * *

Китмә, дисең, тик бик азга гына
Тукта!
Китмә, дисең,
Карашыңны тойыйм тагын да,
Китмә, дисең, кулларыңны тойыйм,
Сулышыңны тойыйм янымда.
Нигә?
Тик бик азга гына?..
Йөрәк дөрләп торган учак ла,

Ташланыйммы, гомерлегең булып,
Бердәнберең булып кочакка.
Китмим мәллә язмышларның
Еллар упкынына үч итеп,
Калыйм мәллә тик синеке булып,
Барысын да ташлап көч житеп?
Калыйм мәллә?
Соңмы?
Артык соңмы?
Ах, язмышлар уен түгел лә...
Китәм, димәк, ләкин барыбер калам,
Үкенечең булып гомергә.

* * *

*А.Жигулиннан*

Яңгырдан каралган йортлар,
Тукран яра талны,
Кояш кар белән көн елый
Сизенеп якын язны.

Янымнан гына ул килә
Серләрен сөйләп миңа,
Язгы яңгыр җепшек карга
Челтәрләр чигә-чигә...

И остасың да сөйләргә,
Сөйлә, ә мин тыңламыйм.
Сонлаган язлар шикелле,
Сонладың шул, сонладың.

Болар — бар да якын иде:
Күзләрең зәңгәр күктән,
Ә шулай да еллар белән
Ул чаклар инде үткән.

Уйсулыкта калган карны
Җил йөри камчыларга.
Кызганыч, вакыт, аһ, вакыт
Чәчелә тамчыларга.

* * *

*А.Блоктан*

Барысын да шаяртуга бордың,
Һәм аңладың бераз соңарып.
Ышанмыйча башың чайкап куйдың,
Эндәшмичә калдың югалып.

Онытырга теләп барсын — күлдең,
Анламаска теләп аңладың,
Как өстәлгә ятып үкседең син,
Алданмаска теләп алдандың.

Китеп бардың, борылып тагын килдең,
Нидер көттең миннән моңаеп.
Ләгънәтләдең һәм борылып киттең,
Мәңгелеккә киттең, мөгаен.

Керфегеңә кунган яшь шикелле,
Үтте гомер, үтте табыну,
Тик чигәмдә калган чал шикелле,
Бетмәс өчен калды сагыну.

## *Исендәме?*

Исендәме, төнлә тирәкләрнең
Кубекләнеп мамык койганы?
Көлә-көлә ак мамыклар кунган
Чәчләремне чәчеп уйнавың.

Көмеш сукмак аша ике як яр
Ай нурында бергә кушылган.
Исендәме, икәү җитәкләшеп,
Китикче без, диден, шушыннан.

Исендәме, гомерлеккә, диеп,
Тирәкләргә йөрәк уйганың.
Су өстенә йолдыз ява иде,
«Уртак бәхеткә», — дип юрадың.

Исендәме?
Бәлки, түгелдер дә...
Агачларны ак бәс сарыган.
Ә мин никтер һаман тирәкләрнең
Мамык койган чагын сагынам.

## *Кояш*

Мине чакырып тәрәз кага,
Тышта яңгырмы икән?
Тәрәзәмдә кояш байый...
Кемнәр язмышы икән?
Моңсуланып, күңел сызлый,
Югалтам төсле нидер.
Тәрәзәмә кемдер кага...
Ялгышам, тышта җилдер.
— Баемачы, кояшым, — дип, —

Кайт, — диеп, — сөю таңы! —
Йөгермә күңел артыннан,
Туктатып булмас аны.
Язмышлар бәрелештеме —
Канланды кинәт шәфәкъ.
Кояшлар якында байый,
Кояшлар байый җәһәт.
Күңелемә сагыш булып
Урала төн карасы.
...Тәрәзәмдә кояш байый...
Туар өчен яңасы.

* * *

Миңа да бит җиңел түгел,
Сиңа да бик авырдыр.
Аяз көннәребез өчен
Сездә хәзер давылдыр.
Миңа гына калдырсаң да,
Күтәрермен ул йөкне.
Тик акланып, ят телләргә
Калдыра күрмә мине.

* * *

Биеклекләргә чакырдым,
Яшенле илләремә,
Күкрәп яңгыр явып үткәч,
Ачылыр гөлләремә.

Киңлекләремә чакырдым —
Ямь-яшел яланнарга.
Кояшым иркәләр иде
Болытлар таралганда.

Зәңгәрлекләргә чакырдым,
Җилләргә, давылларга,
Давыллар тынган арада,
Дулкыннарда уйнарга.

Йөрәгемә ишек ачтым,
Үтәлмәдең тупсасын.
Биеклек давыл, яшеннәр
Иленнән курыккансың,
Сөймәсәң дә, тыныч булган
Үзәнгә юлыккансың.

## Уикэ

Бөдрә генә мамык болытларны
Иңнәремә салдың шәл итеп,
Элпә төсле томаннарга төреп,
Алып китәм, диден, яр итеп.

Учак яктык икәү яр өстенә,
Такыялар бергә агыздык.
Такыялар акты, парлап акты,
Безнең өчен калды ялгызлык.

Иңнәремә болыт-шәлләр салдың,
Томаннарга мине урадың,
Томаннарга урап, еракларга
Алып китә генә алмадың.

* * *

Һәркемнең үзенекедер:
Көттерүләр — синеке,
Көтүләр, өзелеп сагыну,
Өметләрем — минеке.

Һәркемнең үзенекедер:
Сагындыру — синеке,
Иелмәс баш һәм горурлык,
Яратсам да — минеке.

Авыр булса да кирәктер,
Син бит гел кешенеке.
Ике якка юл каера,
Һәркемнең — үзенеке.

* * *

Ташулар булып таштым бит,
Җитмәде үзәннәрең,
Яшеннәр булып сызылдым,
Егылды имәннәрең.

Сандугач булып сайрадым,
Отралмадың җырымны,
Вулканнар булып кабындым,
Сакламадың җылымны.

Кадеркәйләрен белмәсәң,
Түгелә бәхет булып,
Йөрәгеңә йөрәк сыймый —
Кабынам йолдыз булып.

# Язмышлар

...Йолдызга йолдыз бәрелде,
Чыңлап куйды күк йөзе...

*Г.Әхмәтхуҗина*

Сызылып йолдызлар төшә,
Бүген йолдызлы явым.
«Бәхетле бул», — дип әйтәсең,
Йолдыз атылган саен.

Зәңгәр күк — ул үзе тормыш,
Бер якты, бер караңгы,
Ә йолдызлар үтә бары
Тормыш биргән араны.

Һәрбер йолдыз — үзе язмыш,
Яртысын эзли күктән,
Галәмнәрне гизеп, айкап,
Очраша яры белән.

Законнарны, кануннарны
Ватып бер табышалар.
Бер секундка көл булырга
Барыбер кавышалар.

* * *

Ул синең ялгышың, диләр,
Таплаучың, кара таңың,
Ул синең нахагың, диләр,
Бәхетең түгел, кайгың.

Кара кайгым да кадерле —
Иң зур бәхетем кадәр,

Таңнарым кара булса да,
Төннәрем тоташ зәңгәр.

Ялгышым булса да якын,
Синеке, минеке ул.
Үзем сайлап алган язмыш,
Өлешкә тигән түгел.

Син минем кара кайгым да,
Кояшлы ахагым да,
...Таплаучым да, аклаучым да,
Хагым да, нахагым да.

## Ничек бармын, шулай ярат

Башкаларга булыйм, әйдә,
Бер гайбәт сүзе генә,
Үзең генә бел син мине
Һәм аңла үзең генә.

Таны мине үзең генә,
Аер төн карасыннан,
Карашымны эзләп тап син,
Мең күзләр арасыннан.

Серле дөнья бул син миңа, —
Мәңге ачылмас тылсым,
Юллар читкә каерса да,
Ерак якыным бул син.

Күңелемә канат куяр
Йөрәгем моңнары бул,
Болытлы да, кояшлы да
Иң матур җырларым бул.

Бер кеше дә белми торган
Күңелем өмете бул,
Минем өчен гади түгел,
Әкият егете бул.

Тик миндә генә ялгышма,
Мин түгел иң зур йолдыз,
Юк, серләр эзләмә миннән,
Мин гади генә бер кыз.

Йолдыз димә, кояш димә,
Алтын да көмеш димә.
Ничек бармын, шулай ярат,
Бары шул килеш кенә.

## Кыюсызлык

Елмайды, каршыма килеп,
Биергә кулын сузды.
Кире кактым (ошый иде) —
Их, мине, кыюсызны.

Кичләрен тәрәз төбендә:
«Чык», — диеп, гармун сызды.
Пәрдә читен күтәрмәдем —
Их, мине, кыюсызны!

Ялгызымны очратты да:
«Ал», — диеп, йөрәк сузды.
Җавап бирми китеп бардым —
Их, мине, кыюсызны!

Ятлар белән килә дигәч,
Түзеп сез торырсызмы?

Юлларына чыктым үзем:
Күрсеннәр кыюсызны!

Ят өчен яратмадым, дим,
Шыл, кызый, калдыр безне...
Сөйгәнем миңа карады,
Елмаеп кулын сузды —
Кире кагарга оялдым —
Их, мине, кыюсызны.

* * *

Син күкләрдән җиргә төштең инде,
Төшләремнән күчтең өнемә.
Өнемә дә түгел, бигрәк гади
Кеше булып кердең көнемә.

Мин көннәрне төнгә әйләндереп,
Һәм төннәрне көндез көткәндә,
Бу чынбарлык шушы тылсымнарны
Синең акыл аша үткәргән.

Ә ул тылсым нәфис чәчәк кебек,
Ачылалмый — сизгер салкынга.
Гади учак итеп карагансың
Тылсымнардан туган ялкынга.

Көннәремә йолдыз булалмадың,
Кояш булалмадың төнемдә.
Син күкләрдән җиргә төштең инде,
Хыялымнан күчтең өнемә.

# Синең белән һәм синсез

Сөю бирдең һәм мин, шашып,
Кояшлы җырлар яздым.
Күпләргә шатлык өләшеп,
Гел җырлап торды сазым.

Яшеннәр алтын нур иде,
Бер бәйрәм иде давыл,
Җәйгор хәтерләтә иде
Алмаз ташлы билбавың.

Син юк хәзер, әрнү белән
Яңа көй юллый куллар.
Җилгә бөгелгән имәндәй,
Ыңгыраша бу кыллар.

Яшеннәр — утлы чыбыркы,
Тамчылар энҗе түгел,
Җәйгор, утлы кыршау кебек,
Ураган күңел күген.

Һәм сазымда өр-яңа көй,
Ул упкын, дәрья сыман,
Ләкин ул инде күп тапкыр
Көчлерәк тәүгесеннән.

Шатлык, бәхет кенә түгел,
Сагыш та биреп киттең.
Сөеп ярты җырчы итсәң,
Ташлап бербөтен иттең.

* * *

Кукләремне телеп яшен үтсә,
Күкрәү узса минем таңымнан,
Ярдәм кирәк, коткар мине, диеп,
Мин чакырмам сине, чакырмам.
Тик яшеннәр үтеп, кояш чыкса,
Юлларыңа чыклар тезәрмен,
Өметемне җәйгор итеп элеп,
Мин көтәрмен сине, көтәрмен.
Көз килгәндә, моңсу көннәремдә
Шатлык, кояш китсә янымнан,
Җил туздырган буш бакчама чыгып,
Мин чакырмам сине, чакырмам.
Тик күңелдән генә төнге күкне
Күзләреңә синең тиңләрмен,
Өстәлемә соңгы гөлләр җыеп,
Мин көтәрмен сине, көтәрмен.
Тәрәзәмне боз катламы күмсә,
Җилләр үтсә тиеп янымнан,
Салкыннардан мине арала, дип,
Мин чакырмам сине, чакырмам.
Килмәс булсаң, сиңа сиздермәм дә,
Юлларыңнан читкә китәрмен.
Тыным белән тәрәз бозын арчып,
Тик барыбер сине көтәрмен.

* * *

Ничә кат очраштык, ничә кат хушлаштык
Тормыш дип аталган күперда.
Сагынсын, диепме, үкенсен, диепме,
Бу юллар ник тәңгәл китерә?!
Син юллар чатында, офыклар артында
Каласың кайчакта күмелеп,
Төшләргә керәсең,
Сагынасың, күрәсең,
Ут-яшен угыдай күренеп.
Мин сине сагынып эзлимен һәрвакыт,
Табам да яңадан югалтам.
Ә аннан көтәргә, көтәргә, көтәргә
Чаң баскан, кар баскан юллардан.
Күңелләр янәшә, тик аерым чыгабыз
Тормыш дип аталган күпердән.
Үкенсен, диептер, сагынсын, диептер,
Бу язмыш аймылыш китергән.

* * *

Учагымда ут сүрелеп бара —
Утын ташлаучы юк,
Җан өрүче юк.
Туңган миләш пыялага чиртә —
Тәрәз ачучы юк,
Хәл белүче юк.
Соңгы өмет кебек янып, дөрләп,
Йолдыз сызыла күктән —
Кул сузучы юк.
Тупсам сине көтеп боек тора.
...Атлап керүче юк.

* * *

Кайлардан үтте юлларың,
Кайда йөрдең адашып?
Сиздермичә килеп кердең,
Күңел капкасын ачып.
Шакымыйча килеп кердең,
Көтмичә каршы алам,
Күңелемә шатлык түгел,
Сап-сары сагыш сарам.
Белеп торам, сизеп торам,
Тик сагыш белән калам.
Сиздермичә килеп кердең,
Китәчәгеңне беләм.
Сөюемне чәчкә итеп,
Кулъяулыгыңа чигәм.
Тик гафу да үтенмә син,
Үкенмә дә үткәнгә,
Белдермә дә, сиздермә дә,
Хушлашма да киткәндә.
Киткән чакта борылма син,
Кала бәхетем, сынып, дип,
Шакымыйча килеп кердең,
Хушлашмыйча чыгып кит.

## *Ялгызың каласың ла*

Мамык шәлеме ябынып,
Җиңел тун кигән идем.
Чит атларда бураннарда
Адашыйк, дигән идем.

Утырмадың атларыма,
Җилеп үттем яныңнан.

Хәзер килеп нигә тоттың
Атларымның ялыннан?

Юлларымда — син тагын да,
Туктаргамы, нишләргә?
Очаргамы сине алып,
Буран купкан төшләргә?..

Юк, кирәкми, сугам атка.
Ялгызың каласың ла...
Ә мин очам чәчрәп торган
Бураннар арасына.

* * *

Юк, берни дә безне бәйләмәде:
Очсыз вәгъдә, матур алдаулар.
Күңелне дә берни кырып тормый:
Кирәкмәгән төер, ялгаулар.
Күзләрең дә күптән онытылды,
Күмелгәндәй томан артында.
Якты бер нур, матур бер истәлек
Торып калды синең хакында.

* * *

«Мәңгелегем!» димә миңа,
Бәгырьләремне телеп.
Мәхәббәт тә касәдәге
Син салган шәраб кебек.

* * *

Төшләреңә керсәм әгәр,
Килер, дип юрама да.
Ятлар белән бәс коенам
Караңгы урамнарда.

## Төш

Безнең мәхәббәт йолдызы
Атылган иде күктән,
Кулымда кулың җылысы
Суынган инде күптән.

Синең сәлам хатларыңны
Югалткан кебек идем.
Сине югалткан күңелне
Юаткан кебек идем.

Соңгы шат, салкын көлүең
Күңелдән чыккан иде,
Йөрәк сине, ак кәгазьдәй,
Хәтердән ерткан иде.

Бүген килеп кинәт кенә
Тынычлыгымны телдең:
Син көлеп түгел төшемә,
Сагышлы булып кердең.

* * *

Кайда булды үкенүләр,
Сабырлык, акылларым?
Яшенле янгыр шикелле,
Чикләрне боздың тагын.

Ничә еллар биләмәләр
Биләдек ике ярда,
Бер үк диңгезгә ашкындык
Икебез ике салда.

Икебез бер үк кояшны
Аерым каршыладык,
Уртак хисләрне сиздерми
Аерым камчыладык.

Горурлыклар киртә булып,
Бүлделәр ике якка,
Мин бүтәнгә бер елмайсам,
Син көлдең җиде ятка.

Мин карасам, син борылдың,
Син карасаң — мин читтә,
Ашкынулар ватылдылар
Бәрелеп салкын чиккә.

Тәүбәләр ирек куймады,
Акыллар тотты кулдан,
Ничә тапкыр уктаилдык та,
Туктадык ярты юлдан.

Менә тагын чикләр бозып,
Чакыра яшеннәрең.
Давылыңа җавап итеп...
Мин җәйгор әзерләдем...

Онытылсын үкенүләр,
Сабырлык, акылларым.
Мең киртәләрне җимереп,
Каршыңа барам тагын.

* * *

Ромашкалар, кыңгыраулар иле,
Шуннан эзли сине карашым,
Әллә минсез генә сөюебез
Дөньясына кереп адаштың?

Әллә яшеренденме юри генә,
Чыгар өчен кинәт юлларга?
Гаепле җан кебек, кыңгыраулар
Кагылып-кагылып китә кулларга.

Ромашкалар, кыңгыраулар иле —
Уртак иде бу ил тугайда,
Ак таҗларны йолкып юрамадык,
Без ышана идек болай да.

Кагылмыйк без хәзер ул гөлләргә,
Бәхетлеләр аны җыярлар.
Ромашкадай ак ышаныч калсын,
Кыңгыраудай зәңгәр хыяллар.

* * *

Яхшылыкта, яктылыкта
Хәтереңдә булмасам да,
Авыр чакта уйла мине,
Уйла мине кыен чакта.

Телсез, өнсез, сүзсез генә
Көч бирермен арыганда,
Эндәш миңа, чакыр мине
Бәлаләргә тарыганда.

Канатларың каерылса,
Мин булырмын ак күгәрчен,
Талпынырмын, кагынырмын,
Болытларда ял итәрсең.

Җаннарыңны көек басса,
Мин булырмын кояш нуры.
Дулкыннардан, упкыннардан
Тартып алыр минем кулым.

Мин сине чакырмам бер дә,
Хәтта иң кара таңымда,
Юк, мин синең исеңә төшмәм
Бәхетең бөтен чагында.

Яхшылыкта, яктылыкта
Хәтереңдә булмасам да,
Кыен чакта уйла мине,
Уйла мине авыр чакта.

* * *

Кайгыларны, рәнҗү, үпкәләрне
Төен итеп төйнәп күңелгә,
Юлга чыгам тагын, таныш вокзал,
Борылышка керәп күмелә.

Тынгы белмәс уйлар томан белән
Тәгәрмәчкә килеп урала.
Без йөрегән таныш сукмакларга
Яңгыр катыш бозлы кар ява.

Карларыннан, бозы, яңгырыннан
Араларга иде бу көнне.
Тик булмый шул: язлар ерак инде,
Юкка гына хәзер үкенү.

Кайгыларым күчеп күз яшенә,
Аксын әйдә, нигә юату?
Бу дөньяда иң авыры — көтү,
Икеләтә газап — югалту.

* * *

Әй борчыла күңел, әй давыллый,
Әйтерсең лә ярсу агымсу.
Үткәннәрнең өнсез эзләренә
Алып килде тагы сагыну.

Ялкыннары күптән сүрелсә дә,
Ташу утырса да ярына,
Учакларның салкын кочагына
Җил исә дә тагын җан өрә.

Борчылма да, күңел, давыллама,
Үткәннәрнең иле — үткәндә.
Төшләремә керәп үпкәләмә,
Күзләремнән ятлар үпкәндә.

* * *

Йолдызлар берни дә аңламый,
Күз кысты безнең баш очында.
Үпкәсез, күз яшьсез, каргышсыз,
Соңгы кат аерылдык шушында.

Ап-ак бәс, көмеш бәс җемелди
Битараф салкын ай нурында,
Күрмәскә тырыша бәхетнең
Калырын үткәннәр җырында.

Үз булып һәм инде чит булып,
Калырны аңладык шушында.
Тын гына өшегән кулымны
Соңгы кат җылыттың учында.

Кирәкми, туктатма, чакырма,
Үкседе бары тик җан гына.
Табынып йөрәкләр йөрәккә,
Хушлашмый аерылдык мәңгегә.

* * *

*А.Ахматовадан*

Тәрәзгә пәрдә кормыйм мин —
Куренсен күңел кугем.
Син миннән китәлмаганга —
Күңелле миңа буген.

Үз-үзеңә ачуыңнның
Аласың миннән үчен.
Мин синең йокысыз төнең,
Сагышың булган өчен.

* * *

Иелә-бөгелә үсә микән
Кырда ат кузгалагы,
Әүвәлгеләр искә төшеп,
Күңелең кузгаламы?

*Халык җырыннан*

Әүвәлгеләр искә төшми,
Күңелем шундый тымык.
Кырда үскән тузганакны
Җил алып киткән кебек.
Минем күңелем шикелле
Кайтмасын сизеп кабат,
Үкенми, көтми, чакырмый,
Кулын болгап озаткандай,
Тирбәлә ялгыз сабак.

## Кара кош

Әйтерсең тәүге югалту,
Йөрәк әрни дә тора,
Кайгы кара кош шикелле,
Күңелгә оя кора.

Әйтерсең кыш уртасында
Яз кабатланган иде,
Ак күгәрчен кебек сөю
Бер канатланган иде.

Бөтерелде, талпынды да
Югалды зәңгәр күктә,
Сызланма, күңел, син белдең,
Килмәсен аның күпкә.

Хәзер күңел түрләремә
Кара кош оя кора,
Бу соңгы югалту кебек,
Йөрәк әрни дә тора.

* * *

Таң алдыннан тагын буран,
Март аеның соңгы җиле.
Карамыйча тамчыларга
Ак кар белән күмә җирне.

Өерелә, бөтерелә,
Әйтерсең лә кыш арада.
Күңелемә карлар ява,
Салкыннардан кем аралар?

Яз яз булыр, соңгы буран
Соңгы тапкыр бөтерелер,
Күңелемә яуган карлар
Кайчан туктап, кайчан эрер?

* * *

Еллар аша, юллар аша
Мин сиңа дәштем бүген,
Син минем гомерлек бәйрәм,
Мәңгелек җырым минем.

Танымадың тавышымны,
Өздем телефон өнен.
Син мине мең гамь эченнән
Танырга тиеш идең.

Сагынырга, онытмаска
Бары син хаклы идең,
Син минем гомерлек газап,
Мәңгелек моңым минем.

Акыл белә: җеп очы буш.
Йөрәк тыңламый мине:
Буш телефон өне кебек,
Һаман чакыра сине.

* * *

Менә синнән бары шушы калган:
Өем кәгазь, шуны актарам.
Менә кипкән чәчәк, бөртек сәдәп,
Көндәлекләр, хатлар, котлаулар...

Һәрберсендә синең булмыш ята,
Синнән бер уй, бер моң, бер фикер.
Күп ноктлалар, сорау, сүзсез өндәү,
Күп билгеләр сине бар итәр.

Исемә алсам, вакыт кадерләрен
Белеп бетермәдем мин — исәр.
Үткәннәрнең җансыз кочагына
Хатирәләр дигән җил исәр.

Җил исәр дә тынар, мең мәшәкать
Тагын салыр үзенең кынына...
Тик барыбер синең белән бергә
Җитеп барам гомер кырына.

Син яшисең миндә, бар тирәмдә,
Төнге күктә, җирдә, һавада.
Кумә алмый чанга сине вакыт,
Исем китә, искә алам да.

Синнән калган истәлекләр миндә,
Ә соң минем
Үткәннәрне кемнәр актарыр?
Кемнәр ачса, кемнәр барласа да,
Миндә — син һәм бездән җыр калыр.

* * *

Юк, кайтарып булмый үткәннәрне,
Ике какмый ярга бер дулкын,
Үткәннәрнең эзен эзләп килдем,
Үткәннәрнең эзе сап-салкын.

Кадерләрен белер гомерләрдән
Үтеп киттек ятлар җитәкләп,
Ә үткәндә, ятим бала кебек,
Үксеп калды безнең мәхәббәт.

Үткәннәрне эзләп йөрмә, диеп,
Җил йөгерә минем эземнән,
Үткәннәрне ташлап китеп була,
Ләкин булмый китеп үзеңнән.

# III

*«...Гомеремнең җәй уртасы,*
*Бар югалту, табышлары.*
*Кукрәүләре кукри әле,*
*Салмаклана агышлары...»*



* * *

Әй дөньяның матур чагы,
Яшь чагы, яшел чагы.
Сүрән-сүлпән түгел көннәр,
Болытлар — яшен чагы.

Кыздырса, кыздыра кояш,
Ә яуса, коеп түгә.
Аннан соң бәллүр офыкка
Җәйгор көянтә элә.

Кояш күмелә дә балкый
Офыкка качар-качмас,
Ә кырда ялан гөлләре
Керфеген ачар-ачмас.

Әй дөньяның матур чагы,
Сөюе тулы вакыт.
Бер сүз әйтсәң дә чайкалып,
Күңеле түгелер вакыт.

* * *

Гомеремнең җәй уртасы,
Бар югалту, табышлары.
Күкрәүләре күкри әле,
Салмаклана агышлары.

Гомеремнең җәй уртасы,
Чәчкәләре тере әле.
Тик юк инде өмет кебек,
Ачылмаган бөреләре.

Гомеремнең җәй уртасы,
Кичләремнең җиләслеге,
Ләкин инде сагындыра
Яшьлегемнең иләслеге.

Сагындыра ташкын-агым,
Ярсу, күкрәү, яшен теле...
Нәкъ уртасы, соңы түгел,
Синең сының — тәүге бөре.

* * *

Курайларның сут тутырган мәле,
Тугайларда — чәчкә җырлары,
Офыкларда — җәйгор канатлары,
Болыннарда — яңгыр моңнары.
Тарафларның колач җәйгән мәле,
Зәңгәр күктә — төпсез тирәнлек,
Чәчелмәгән-түгелмәгән килеш,
Бар хисләре тулы тирәлек.
Олыгаеп калган сыман дөнья
Сабыр-салмак нурга коенган.
Әйтерсең зур сергә төшенгәндәй,
Бар табигать тынган, тыелган.
Курайларны моң тутырган чагы,
Акыл һәм хис камил дөньяда.
Бала көткән ана кебек, дөнья
Үзалдына үзе елмая.

* * *

Табигатьтә инде көз тавышы,
Күл өстендә казлар каңгылдаша,
Бик биектә, җете зәңгәрлектә,
Киек казлар оча шул күл аша.

Кайда икән, кайда бәбкә чаклар,
Офыкларга житәм дигән язлар?..
Моңсу карап күл өстендә кала
Канаты киселгән казлар.
Таяныч та түгел кисек канат,
Юкка гына казлар талпыныша.
Ә еракта, ак жеп булып балкып,
Киек казлар чыга офык аша.

## Очкынлана яфраклар

Офыкларда көзге кояш
Сүнде сибеп ал нурын,
Баш очында ак торналар
Калдырып үтте жырын.
Алар алып китә сине,
Торналарда — канатлар,
Ә усакта, хушлашкандай,
Очкынлана яфраклар.
Хушлашма үткәннәр белән,
Син — минем күрәчәгем.
Мин синең үткәнең түгел,
Бүгенгең, киләчәгең.
Язлар алып кайтыр сине,
Мәхәббәттә — канатлар.
Тик усакта, хушлашкандай,
Очкынлана яфраклар.

* * *

Урманнарда алтын туйлар бара,
Күңелгә дә иңә сары моң.
Жилләр, яз таптырып, көз түрендә
Күрекләрен өзә гармунның.

Югалганны миннән таптырма, җил,
Һәр өзелгән яфрак — ялгызлык,
Гармун түгел, ике чиктә инри
Шул ялгызлык белән табылдык.

Сарылмагыз, миңа, сез, яфраклар,
«Калдырмачы», — диеп инрәнеп.
И яфраклар, минем җанда да бит
Шул ялгызлык килә сөйрәлеп.

* * *

Акрын гына, ялкау гына
Яфраклар тузып йөри,
Кемнәрнеңдер учагыннан
Ак төтен күктә эри.

Көз көнчел хуҗабикәдәй,
Җир йөзен усал күзли,
Зәһәрләнеп ажгыра да
Туздырырга гел эзли.

Әй ярсына, әй тузына,
Туңдырырга көз йөри,
Ә кемнәрнең учагыннан
Ак төтен күктә эри...

## Учак

Ар якта бер учак,
Ар якта бер учак,
Кемнедер сагынып талпына,
Әйтерсең сөюгә сусаган бер йөрәк,
Шул учак үзенә чакыра.

Өметтәй бер яна,
Йә эреп югала,
Яңадан йә дөрләп кабына,
Килерме, килмәсме, —
Барыбер бәхетле
Көтәргә кешесе барында.

Ар якта бер учак,
Ар якта бер учак,
Сүнде ул калдырып төтенен.
Йә сүнде өмете,
Йә килде көткәне,
Йә кадерен белмәде көтүнең.

* * *

И күзләрнең моңсу сарылыгы,
Бу дөньяга нидер тулмыймы?
Йә моңсусыз гына, йә сарысыз,
Йә күзләрсез генә булмыймы?
Яңа гына язлар ярсу иде,
Бөреләре шартлап ярылган.
Ни арада бакчам түрләренә
Бу сарылар килеп сарылган?
Яңа гына таңнар алсу иде,
Кәккүкләре белән өздергән,
Кай арада офык якларына,
Соры пәрдә элеп, күз кергән?
Кайчан гына күңел ярсу иде,
Җаннар чөеп, җаннар яндырган...
Кай арада, кайдан җилләр исеп,
Күңелемә моңнар калдырган?
Әй син, күзнең алтын кыңгыравы,
Чыңлавында язның тавышы,
Син булмасаң, күңел канатыма
Тимәс иде күзнең сагышы.

* * *

Йөгерек җилләр салмакланган сыман,
Тик шулай да куе таңнарда,
Анда-санда иртә чалны күреп,
Каеннарны төрә томанга.

Җил тарткалый алтын яфракларны,
Сары келәм түшии юлларга,
Тик гашыйклар гына йөри торган
Сукмакларны ача дөньяга.

Ул яфраклар ташлый су өстенә,
Дулкын кага кабат ярларга,
Җәй сер булган миләш тәлгәшеннән
Ялкын ургый әллә кайларга.

Шаян җилкәй ары йөгереп китә,
Толымнардан сөеп уза да,
Тәү кат ары үпкән сылу кебек,
Куаклыкта балан кызара.

* * *

Ә кылганнар инде бәс төсендә...
Агачларда балкый чаллану.
Озын көзләр аша, буран аша,
Бик еракта әле яңару.

Чәчәкләрнең гомер киче җитә,
Ак тажларны инде тут баскан.
Май кичләрен хәтерләтеп һаман
Күбәләкләр оча ичмасам.

Соры томан җирне каплап яткан,
Күк йөзләре тора каралып.
Су өстендә казлар каңгылдаша,
Яр буйлары тоташ ак мамык.

* * *

Көз инде, көз, болыннарга
Салмак кына яфрак ява.
Ни хикмәт бу — сары келәм
Арасында җиләк яна.

Көннәр чуак, каен җиләк,
Су буенда — каз тавышы.
Җиләк пешә. Табигатьнең
Әллә инде бу ялгышы?

Көз уртасы, тиздән ак кар
Каплап китәр бу болынны.
Очкын-җиләк, үзәм, дисәм,
Тартып алам мин кулымны.

Көз инде, көз, су өстенә
Каз мамыгы, яфрак төшә.
Сонга калган сөю кебек,
Берчә качып, йә ут яныл,
Елый-көлә җиләк пешә.

* * *

*С.Есениннан*

Алтын нурга чумган көяз урман,
Көзге җырын көйли каенлык.
Торналарның соңгы җырларында
Беркем дә юк искә алырлык.

Ә кемне соң алар искә алсын?
Бу дөньяда һәркем — юлаучы.
Күл өстендә ай һәм киндер чугы
Үткәннәрне сагынып елаучы.

Торналарны мин озатам ялгыз,
Җил аларны куа еракка.
Шук яшьлекне уйлап уйчандыр мин,
Үкенеч юк ләкин йөрәктә.

Үкендерми зая үткән еллар,
Зәңгәрлекләр уңды шикелле.
Учак төсле миләш тәлгәшләре
Җылыталмый ләкин беркемне.

Саргайса да, кабат шыта үлән,
Һәм миләшләр кабат кабына,
Моңсу сүзләр сары яфрак кебек,
Ирексездән генә агыла.

Вакыт җиле барысын да күмеп,
Калдырса да үткән иләндә...
Сез, әйтегез... көзге алтын урман
Җырлады, дип, каен теләндә.

## Яңа ел алдыннан

Җылы да юк күңелемдә,
Салкын да юк, каргыш та юк.
Күңел ап-ак кәгазь сыман,
Югалту да, табыш та юк.
Үткәннәр юк, киләчәгем —
Башланмаган бәхет кебек,
Учак кына — берчә алтын,
Берчә куе кара дегет,
Очкын гына ялтлап сүнә,
Синең таныш сының кебек.
Төшме, өнме бүгенге кич,
Сагышларны утка салам,
Бөтерелеп, ялкын ялмап

Югалганын карап калам.
Сабыр гына искә алам,
Тыныч кына хатлар ягам.
Башланмаган бәхет кебек,
Яңа елны каршы алам.

* * *

Хушлаша көз, китүендә —
Үкенече, сагышы.
Сары яфрак ява җиргә —
Көзнең нурлы нәкыше.

Үләннәрнең чал чәчендә
Кырау күренеп кала,
Ертык болыттан бер учма
Җылы нур төшеп ала.

Җылы нур... Бәллүр тамчылар...
Җир — томан куенында.
Тамчылар — алдаткыч өмет —
Өянке толымында.

* * *

Хыянәтче, салкын, аяусыз көз
Атлар җигеп чаба туйларга.
Тик гашыйклар гына йөри торган
Сукмакларны ача дөньяга.

Сары буран җилә, эзләр яба,
Ялкын чәчә миләш, баланнар.
Хатирәләр монда, ләкин эзләр
Бу сукмакта күмелеп баралар.

Яфрак оча, яфрак бию бии,
Җил очырта, чәчә барысын.
Тиле күңел, син дә кушылып бие,
Эзләреңне бәлки табарсың.

Таныш сукмак монда кала, диеп,
Җил, юлымнан мине туктатма.

Китәм әле, китәм, ярсу язлар,
Яңа сукмак көткән бер якка.

## Серле җыр

Шаян нур булып төштең учыма,
Урамда майның чәчкә бураны.
Тотып та булмый, китеп тә булмый,
Юк, алалмыйм мин нурдан кулымны.

Урап-уралып сүттең толымны,
Түгелә шомырт, гүя ак күбек.
Тотып та булмый, узып та булмый,
Әйтерсең син җил, иркә җил кебек.

Серле моң булып кердең җаныма
Үзеңнән-үзең биләп күңелне.
Отып та булмый, онытып та булмый,
Әйтерсең син җыр, син җыр шикелле.

* * *

Көмеш табанлы чаналар
Ак карда чыжлап бара,
Артларыннан игезәктәй,
Зәңгәр юл ятып кала.

Энҗеләнгән ак каеннар
Моңайган кызлар кебек,
Озатып карап калалар,
Эзләргә бәсләр түгеп...

Бәсләр — күз яше кебек.

# IV

*«...Әй шулай да юка иңнәремдә*
*Пәйгамбәрләр йөге йөретәм,*
*Кабатланмас фани бу дөньяның*
*Һәр мизгелен бакый җыр итәм...»*



* * *

Үз иләндә пәйгамбәрләр булмый,
Булалмадым мин дә пәйгамбәр,
Булды алар, булды, тик мин түгел
Өлешенә көмеш тигәннәр.

Мин яраттым сине әрнү белән,
Биш газапка булды бер рәхәт,
Булдың миңа ятлар яры кебек,
Бер җавапсыз гүя мәхәббәт.

Сөйкемле зат булалмадым синдә,
Ни кылсам да, күңел кителде,
Үз өендә үги ана белән
Үсеп килгән бала шикелле.

Денем өчен, дисәм, көнем өчен
«Әпипә»гә дөнья биетте,
Гөрләп торган табын түрләремдә
Җыен әрсез җырлап туй итте.

Җыр башласам, җырны гайбәт күмде,
Сүз сөйләсәм — кабер салкыны,
Йә битараф тынлык таш коймадай:
«Син — чит, син — ят», — диеп талкыды.

Ә шулай да юка иңнәремдә
Пәйгамбәрләр йөге йөретәм:
Кабатланмас фани бу дөньяның
Һәр мизгелен бакый җыр итәм.

Үз иләндә пәйгамбәрләр булмый,
Булмасам да мин дә пәйгамбәр,
Минем авыр йөктән хәзинәсен
Үзе алыр үзенә тигәннәр.

# Мин — хатын-кыз

Мин — хатын-кыз, әле шундый чагым:
Җырлы чагым, моңлы, бәһале,
Күңел тандай нурлы, кылдай нечкә,
Әйтерсең лә бәллүр аһәңе.

Мин — хатын-кыз, усал кагылмагыз,
Фани дөнья сезгә тар кебек,
Саксыз сүздән күңел кителмәсен,
Яшен кискән яшел тал кебек.

Тупаслыктан мин каралам, көям,
Усалланам, нигә ул сезгә?
Ир булыгыз, мин хатын-кыз булыйм,
Әйләндермәгезче әрсезгә.

Мин — хатын-кыз, кадер белгән өчен
Тугрылыкка җанын тапшырган,
Сөю белән мин яхшырак булам,
Матуррак булам, яктырам.

Ачы телләр, пычрак уйлар белән
Кагылмагыз, күңел чаң кебек.
Мин — хатын-кыз, бары яратыгыз,
Минем вакыт кыска таң кебек.

## Шәмәхә төн

Шәмәхә төн тынган күңелемне
Тагын адаштырды. Күпкә микән?
Тиле йөрәк, сагыну, әрнүләрең
Әле күптән генә үткән микән?

Шәмәхә төн, алмаз-йолдызларны
Кабат җанда минем кабызмачы,
Март аеның салкын тамчыларын
Туңган йөрәгемә тамызмачы.

Шәмәхә төн, үтәрсең син тиздән,
Беләм синең күпкә түгеләңне.
Ярсытмала югалтулар белән
Өзгәләнеп беткән күңелемне.

Шәмәхә төн, мине адаштырма,
Салма мине килер газапларга!..
Шәмәхә төн, коткар, дия-дия,
Үзем керәм синең кочакларга.

* * *

Күңелемне тагы яз биләде,
Мең төсләре белән сирпелде.
Яңа булып, көтелмәгән булып,
Мәңге биләмәгән шикелле.

Моңсу күзләр булмаган да кебек,
Сарылары белән сагышы.
Кайда илтә, кайда күмеп куя
Кайгыларны вакыт агышы.

Талпына да очып китә алмый,
Әйтерсең лә сынган канатлар,
Агачларның очларында гына —

Көздән калган сары яфраклар.
Син дә шулай көздә торып калдың,
Сары иде ул чак тарафлар.

Агачларда яңа бөре бүртә,
Яз яшьнәде җанда тагын бер.
Дөнья тагын бетмәс өмет кебек,
Яшел шәлен иңгә ябыныр.

Көзге яфрак тиздән өзелеп төшәр,
Тик ул инде миңа барыбер.

## Колын

Җил белән яфрак куыша,
Кояшлы көзге болын.
Тупылдатып баскан саен,
Шөлдергә колак сала да
Баш чайкап ала колын.
Күптән аны үзенә тарта
Һәм күрәсе килә бик:
Офык аша ниләр ята,
Әнә тауның түбәсеннән
Кыеп үтә зәңгәр чик.
Җилләрне уза колын,
Ота тояклар җырын,
Шук шөлдер чыңлап ала,
Ял астыннан, мут елмаеп,
Әнисе карап кала.
Тик ни хикмәт, чапкан саен,
Җитә алмый офыкка.
Башын иеп кире килә,
Һәм әнкәсе сабыр гына
Серләр сөйли колынга:
«Офыкны куып тотмыйлар,

Житәм дип чапма, тилем,
Офыгыңның зәңгәр чиге
Нәкъ басып торган жирең».
Әни шаяртадыр, диеп,
Ышанмый аңа колын,
Тупылдап басып ала,
Һәм шөлдер чынлап кала.
Зәңгәр чиккә житәм, диеп,
Жилләрне узып чаба.
Очкыннар чәчә тояк,
Ә офык һаман ерак...

## Яңа йорт сала егетләр

Өй күтәрәләр егетләр,
Уйлашып, жайлап кына.
Яшь килен әйрән чыгара,
Әйрәне — каймак кына.

Тыйнак кына салып бирә,
Күзендә — бәхет тоташ.
Сөйгәненең беләгендә
Ялт та йолт уйный кояш.

Яңа йорт сала егетләр,
Балталар тора көлеп.
Ниргәләр куккә үреләә
Бәхетнең үзе кебек.

Йорт булгач, кунар тәрәзгә
Пәрдәләр актан гына.
Алырга язмасын йортка
Тик шомлы хатлар гына.

# *Дуска*

*Дилә Булгаковага*

Гомер үтә, дускай, үтә гомер,
Елга акмас шулай, җил исмәс,
Чәчләремә менә кырау төшә,
Синекендә ята иртә бәс.

Бар да үтә, кала үткәннәрдә,
Учаклардан кала тик көлләр.
Бездә кала югалтулар белән
Телгәләнеп беткән күңелләр.

Дуслар булды, дус түгелләр булды,
Ә йөрәктә шигырь яшәде.
Төбенәчә эчтек, агу кебек
Гайбәт тулы ачы касәне.

Пардан гына кидек зәңгәр күлмәк,
Сер бирмәдек әллә кемнәргә.
Авыр чакта бары таяндык без
Бер-беребезнең юка иңнәргә.

Гомер үтсә үтәр, җан дускаем,
Зәңгәр күлмәк иштән киик без,
Күңелләрне горур тотып, бары
Шигъриятькә башны иик без.

Төшләкләрдән гомер авышып бара,
Йөрәктә — җыр, чәчтә — ак бәсләр.
Безнең күңел кебек һаман яна
Кар өстендә соңгы миләшләр.

# Кенәри

*Д.Б-га*

Кая синең кенәриең, дускаем,
Кай җирләрдә оча икән кошкаең,
Кай урманга, кай яланнарга киткән,
Әллә инде чит бакчаны үз иткән?
Әй сайрады, әй җырлады былбылдай,
Йокыларыңнан уятты тындырмый.
Гомереңнең иң матур елларында
Кенәрине тыңлап син туймадың да,
Очып килер диеп инде син көтмә,
Үзе барып кергән алтын читлеккә.
Сагышланма, саргайма, син, дускаем,
Читлек өчен яралган ул кошкаең.
Сандугач тавышы белән көйлә ни,
Кенәри булып кала шул кенәри.

* * *

Үтмәс, дисәм, үтә бу минутлар,
Бәхетемнең баштан ашканы.
Күзләреңә карап күзләремнең
Соравыма җавап тапканы.

Ах, күзләрең, күңел йолдызларың —
Упкын сере, яшен яшьнәве,
Минем хыялымның җеназасы,
Минем хыялымның яшәве.

Ах, күзләрең, күңел тәрәзләрең,
Йолдыз итеп чөйде җанымны,
Бәхет, диеп шашсам, кемнәр өчен
Керфекләрең аны яшерде?

Ах, күзләрең, күңел көзгеләрең,
Мин чагылып кына югалам...
Күзләреңә карап тын алам да
Тезләреңә ятып тын калам.

## Үзем хакында

*(Шаяру катыш)*

Мин — хатын-кыз, шигырь язам
Егерменче гасырда.
Урта гасыр — гыйбрәт димә,
Гыйбрәт хәзер — асылда.

Шигырь язарга утырам,
Күңел тулы поэма.
«Уртанчының оекбашы
Тишек», — ди ир. «Кайгырма!»

Кулга энә һәм җеп алам,
Типчегән саен минут.
Бармак арасыннан ага,
Шигырь дигәнне оныт.

Оек әзер. «Күлмәгемнең
Сәдәбе кая?» — ди ир.
«Галстукны тагып бирче,
Һәм магазинга йөгер».

Ир хакы — Тәңре хакы —
Өстәл ябылган күптән,
Инде газәл язам, дисәм,
Мәдхия җырлап китәм.

Ары киләм, бире киләм,
Бакча тулы чүп-үлән.
Каенанам күрсә ни дияр?
Бакчага чыгып китәм.

Аннан үтүк көтеп тора,
Аннан савам сөт-күбек.
Дөнья өтә, шигырь көтә
Үпкәләгән яр кебек.

Инде шигырь язам, диеп,
Кич житкәч өмет килсә,
Кечесе ыштан чылата,
Олысы сорау бирә...

Нигә шигырь жанлы итеп
Яраттың, Хода, нигә?!

Тәлинкәләр, кәстрүлләр
Басып алды — уртада.
Мең ваклыклар түргә уза,
Шигырь кала тупсада.

Рәнжи шигырь, сызлый күңел,
Вакыт йоклап китәргә.
...Иртән тагын — төшке ашка
Нәрсә ижат итәргә?

## Синең сипкелләр

Кояш нурын көлеп тарата,
Нур уйный күзләреңдә.
Мең кояш чыккан төсле бүген,
Мең сипкел йөзләреңдә.

Син барасың нурга коенып,
Бер күрергә җан атам.
Син үтәсең күрми янымнан,
Мин барыбер яратам.

Мең йолдыз керә төшләремә,
Күңелең кемдә генә?
Мең чәчкә керфек ачкан кебек,
Мең сипкел йөзләреңдә.

Син үтәсең минем янымнан,
Күрмисең мине нигә?
Сипкелеңнән тик берсен генә
Бүләк итеп бир миңа.

Кояш нурын көлеп тарата,
Нур уйный күзләреңдә.
Мең кояш чыккан төсле бүген —
Сипкелләр йөзләреңдә.

Йөзеңдәге шул сипкелләрнең
Берсе өчен җан атам.
Берсе белән, йөзе белән,
Мене белән яратам.

## Урман

Илаһи көз. Учак кебек урман,
Әйтерсең ут, ялкын бәйрәме,
Үрелдисәм, куздай төлгәшләрдән
Җанга үтә очкын бәйләме.

Мин урманның җәйге чагын беләм:
Тыныч, җырлы, гүзәл якларын,
Җәй булса да бар хисләре талгын,
Сабыр, салмак, горур чакларын.

Урап йөрдем күпме ул урманны
Мин хуҗадай һәрбер җиренә,
Кунак булдым яшерен сукмакларда
Төшенмичә аның серенә.

Бүген урман шул ук түгел, башка:
Күз моңнары сарган бер күңел.
Хисләрендә моңсу дуамаллык,
Юк, бу инде гади җәй түгел.

Илаһи күз. Очкын чәчә урман,
Тыя алмый шашу балкышын.
Гаҗизмен мин, керсәм чыга алмам,
Ялкын ялмар җанны ялгышып.

## Алтын балдак

Сары күзле алтын балдагым,
Бармагымнан бер дә салмадым.
Син түгелсең ирек сынҗыры,
Алтын кыршау — никах чылбыры.

Алтын кыршау — никах чылбыры
Түгел иден, бүләк нибары.
Сөю дигән утлар ялмады,
Тик бәхеттән торды таңнарым.

Тик бәхеттән торды таңнарым,
Сөюемнән тулды җаннарым.
Калсаң да син җиде ятларда,
Күңелкәем синең якларда.

Күңелкәем синең якларда,
Сагышлардан янган чакларда.
Бармагымда — ядкәр таңнарым —
Сары күзле алтын балдагың.

## Өмет

Баш очында әйләнә дә
Әйләнә тик өмет — болыт.
Көя үлән, көя гөлләр,
Яфракларда тамчы чык юк.

Гүя кайгы иңгә салып,
Башын игән иген кыры,
Кибә күлләр, ә кошларның
Ишетелми моңлы җыры.

Бөреләнгән килеш юкә,
Елый алмый хәтта таллар.
Ятимсерәп ерак калган
Елгасыннан горур ярлар.

Күзләр — күктә, яңгыр кирәк
Көлү өчен, яшь өчен дә.
Кызган тимер кебек һава —
Өмет-болыт баш очында.

## Яңа тәрәзләр

Ак пәрдә — як-якта, бүлмәдә туй бара,
Тәрәзгә сыена сиреньнәр.
Кунаклар гөр килә: «Бәхетле булыгыз!»
Яратып кушылган иреннәр.

Пәрдәләр корылган, пәрдәдә — шәүләләр,
Куркышып дерелди сиреньнәр.
«Мин китәм бөтенләй».
Җавапка тик тынлык,
Авыртып кысылган иреннәр.

Кавышу, аерылу — икесе янәшә,
Гаҗәп тә, аңламый сиреньнәр.
Кемнәрдер бәхетле, кемнәрдер бәхетсез,
Ә туйда тик бәхет телиләр.

* * *

Олыгайта, күзгеләр дә
Нур чәчсә заманында,
Чибәррәк күрсәтәләр,
Тик шәфәкъ таманында.

Олыгайта, вакыт һаман
Гомер йомгагын сүтә.
Тик күңел әйтерсең тәү кат
Гашыйк булырын көтә.

## Каеннар

Каеннарны кайгы төсе, диләр,
Ялгызлыкның, диләр, сагышы,
Аерылуның, югалтуның, диләр,
Юксынуның, диләр, тавышы.

Юк, каеннар бүген шатлык бөркә,
Бәхетләре ташкан, мөгаен,
Толымнарын җилгә сүтеп салып,
Җилгә чәчә чәчен ак каен.

Йөрәк сузган гашыйк кебек гүя
Ул кояшка сузган бөресен.
Ак каеннар сагыш төсе түгел,
Өмет төсе булып йөресен.

## Ике гөл үкенече

Тормышка гашыйк идем мин,
Ышангач һәм яраткач.
Өзделәр, каерып өзделәр
Чәчкәгә йомарлангач.

Тормышка гашыйк булсам да,
Сиздермәдем, яраткач.
Сабакта килеш корыдым,
Өзелми чәчкә аткач.

## Ялгыз тирәк

Су буенда ялгыз тирәк
Көннәрен көнгә тага,
Сары күлмәген чөметеп,
Чәчләрен чайкап ала.

Елгага тама яфраклар,
Агалар, юл алалар.
Бергәләшеп туалар да
Берәмләп югалалар.

Чыршы — яшел, усак — кызыл,
Каенның — ак күлмәге.
Югарырак, тау башында,
Агачларның күмәге.

Әллә яфрак, әллә тамчы,
Әллә яшь суга тама.
Күлмәк итәген чөметеп,
Тирәк чәч чайкап ала.

## Казан дусларыма

Минем килү сезгә бәйрәм булсын,
Бу һәркемгә соры чынбарлык.
Энже кебек эчке якты белән,
Бер балкысын күңел чыңлатып.

Мин учыма салып тупаслыктан
Өшеп беткән ялгыз җанымны,
Сезгә киләм, дәва юллап киләм,
Юллап килгән кебек ярымны.

Мин — хыялый. Ничек бармын шулай
Кабул иткән якын дусларым,
Сезгә киләм үз-үземне юллап,
Яз юллаган кебек кышларын.

Минем килү сезгә бәйрәм булсын,
Ул яктырак булсын таңнардан.
Чишмә кебек яңа җырлар типсен
Бәрәкәтле җырлы җаннардан.

Һәр очрашу безгә бәйрәм булсын,
Тансык булсын дуслар ишеге,
Ә китүем һәрчак сагыш булсын,
Мәңгелеккә киту шикелле.

## Ак тынлык

Күңелем тулы ак тынлык,
Әйтерсең җәй булмаган.
Эленеп калган бакчада
Миләш — муенса, таган.

Күңелдә — кыш. Ни кылсам да,
Җәйне туктаталмадым.
Көрт баса күңел түренең
Иң садә сукмакларын.

Көрт баса. Шомырт иңендә
Җәй хатирәсе калган:
Ятимсерәп җилдә бии
Дивана кебек таган.

Бии, елый, өзгәләнә:
«Онытма берәү барда...»
Ә эзләр күмелеп бара
Кар баскан верандада.

Күңелем тулы ак тынлык.
«Уйла», — диеп кайчак кына,
Җилдә җилферди ялварып,
Миләш-муенса гына.

## Кызыл шомырт

Җырларыңны, юлларыңны,
Елларыңны бер онып,
Учымда мөлдерәп ята
Егерме кызыл шомырт.

Арадагы упкын аша
Минем якка бау ыргыт,
Куз кебек җанны көйдерә
Егерме кызыл шомырт.

Мөлдерәп күзләргә бага:
«Соң булса да ал йолып
Югалган елларыбыздан», —
Егерме кызыл шомырт.

Мең сорауга, мең назыңа
Җавапсыз калам тынып.
Учымнан җиргә коела
Егерме кызыл шомырт.

* * *

Тәрәзәгә маңгай терәп
Килер, диеп юрадым,
Килмәгәнгә елый димә,
Күк елый, мин еламыйм.

Ничә еллар өнсез-сүзсез
Күңелемә урадым,
Ишелә болыт урамга —
Төн елый, мин еламыйм.

Яңгыр ява шәһәренә,
Ташка чәчри хыялым,
Мине сагынып елый димә,
Күк елый, мин еламыйм.

* * *

Кайларда йөрдек икән без,
Нинди сулар эчкәнбез,
Гомер үткәч, кичләр җиткәч,
Бер учма нур микән без?

Кайларда йөрдек икән без,
Сак белән Сок микән без,
Әллә язмышка уч итеп,
Так белән җеп микән без?

Кайларда йөрдек икән без,
Үкенечкә микән без,
Әллә бәхетнең үземе,
Бәхетсезлек микән без?

Кайларда йөрдек икән без...

* * *

Син йоклыйсың, ә мин китәм синнән,
Төшләреңдә мине күр, яме,
Һәм каршы ал минсез генә кичне,
Минсез генә моңсу иртәне.

Өзгәләмәм сине уңга-сулга,
Тыныч булыр, булмас «карышмак»,
Китә миндә синнән серле дөнья,
Ачылмаган яңа табышмак.

Булсын әйдә, мең-мең мәшәкатең,
Ыгы-зыгың шунда исемсез,
Чәчел, түгел, күңел юаткан бул,
Тик бәхетле түгел син минсез.

* * *

Чәчкә кададың чәчемә,
Санадым керфекләрен:
Так киләме, җөп киләме —
Язмышны үчекләдем.

Кануннардан каерып алып,
Сөйлимме серләремне?
Җанымны учка йомарлап,
Яшердем күзләремне.

Чәчкә кададың чәчемә,
Так килә тажы миңа...
«Ярата» чугы төшкәндер
Бүтәннәр өлешенә.

* * *

Әйт миңа сөю сүзләре,
Яшермә сөюеңне,
Эрет син яз кояшыдай
Бу туңган күңелемне.

Әйт миңа сөю сүзләре,
Үтсен ул җанга кадәр...
Күмелим күзең нурына,
Күмелим таңга кадәр.

* * *

Якты күңел тәрәзләрем —
Үтте сөю давыл кебек,
Торып калдың син дә миңа,
Ә күңелгә авыр кебек.

Бүленергә, бүлгәләргә
Бернәрсә дә юк та кебек,
Кызыл түгел бу шомыртлар,
Бу шомыртлар — кара күбек.

Үтте давыл, болыт якын,
Күңел күгем ялтлап тора.
Якын булсаң да, ераксың —
Шуңа сагыш саклап тора.

## Былтыргы көз

Былтыргы көз, былтыргы көз,
Алтын күперләр корды,
Күңелләр — кыл, мәхәббәт — кул,
Кылларда уйнап торды.

Аһ, ул алтын күперләрнең
Моңлы бер чыңлаулары...
Күзгә-күз, җанга, җан багып,
Ул серне тыңлаулары...

Үткән көзнең ак моңнары
Ишелсә дә арага,
Быелгы көз салкынлыгы
Әйләндерә карага.

Әйләнәм дә тагын киләм
Җимерелгән күпергә,
Син якын да, бик ерак та,
Ничек күпер үтәргә?

Күпер генә үтәр идем,
Ятлар кискән арадан,
Ватык күпер өсләрендә
Бәргәләнә минем җан.

* * *

Чәчелмәгән, түгелмәгән әле
Йөрәгемнең ярсу, ташулары,
Кайсы чакта күзләремдә чагыла —
Күңел төпләремдә ташу бары.

Басылмаган, сүрелмәгән хисләр,
Карашларга кара, нәрсә сөйли,

Яңа ялкын булып кабынырга
Учак асларында күмер көйри.

Күзләремә бары кара минем,
Ул вулканга, ул упкынга охшый,
Сахраларда дымга нәүмиз гөлдәй,
Мәхәббәткә минем җаным сусый.

* * *

Яңа елда ташсын ташкын хисләр,
Күңел белән күңел бәйләнсен.
Юк, шәрабтан түгел,
Сөю тулы
Карашлардан башлар әйләнсен.

* * *

Килә-китә, яна яңа мизгел,
Яңа язлар, көзләр, кышларым.
Тик сагынып сезгә сәлам юллыйм
Яңа елда, иске дусларым!

## Сөйләшү

— Мин — тәүгесе, соңы түгел,
Акылым шуны белә,
Тик учың орыну белән,
Тулып пешкән күкрәкләрем
Зеңгелдәп күкне үбә.

— Син — тәүгем дә, син — соңгым да,
Күзләрең миннән түбән,
Иренең кагылу белән,
Ләззәт тулы иңнәреңнән
Акылдан язып үбәм.

# Мизгелләр

Була мизгел, шундый мизгел була:
Эчләремне сызып үтә сагыну.
Шыр ялангач күңел кылларымны
Көйдереп лә ала ачы яну.

Була мизгел, ул мизгелдә кайчак
Кабатланмас бәхет баштан аша,
Бу дөньяда синең барлык миндә
Шатлык катыш моңнар булып таша.

Була мизгел, син янымда мизгел —
Күзләр ачып, күзләр йомган ара...
Табышлар һәм югалтулар белән
Тетрәндереп минем җанда кала.

# Сиреньнәр

Сиреньнәр бүләк иттең син,
Ул көн китми исемнән,
Сиреньнәр хуш исен чәчә,
Ә мин синең, ә мин синең
Исләреңнән исерәм.

Кабатланмас ул көннәрне
Кабат-кабат кичерәм,
Үч итеп айнык дөньяга
Исләреңнән исерәм.

Җаным тулы сиреньнәрне
Җырларыма күчерәм,
Дөньяга сыймас хисемнән,
Дөньяга сыймас хисемнән —
Исләреңнән исерәм.

* * *

Тагын китәм, аерылабыз,
Җаным тулы үпкә,
Өч минут вакыт тапмадың
Бакый мәңгелектә.

Адым гына ара үзе,
(Горурлыклар тиккә)
Ярты-ярты бербөтенбез
Икебез ике чиктә.

Сарыф ителмәгән сөю
Йөрәгемне өтә,
Аерылабыз, иңрәп кала
Фәрештәләр күктә.

Үкендерер, дөнья — фани,
Гомер зая үтә,
Кыеп өч сүз әйталмадым
Бакый мәңгелектә.

## Мин арыдым синнән

Мин арыдым синнән, тупаслыктан,
Очсыз дәгъва, вакльк, нахактан.
Уйнаулардан туйдым синең алда,
Үти алмас хаксыз таләптән.

«Тәрбияләп» мине күп карадың,
Буалмады, булмас шикелле.
Мин ялыктым, әгәр унга чапсаң,
Әзерләргә сул як битемне.

Ах, кайда ул, син Аллага тиңдәш,
Мин алиһә булган вакытлар?

Сөю көзгесеннән торып калды
Челпәрәмә килеп ватыклар.

Мин арыдым синнән, син дә бугай...
Үз-үзенә булмый алдашып.
Безнең сөю ваклык шырлыгында
Калды инде күптән адашып.

Кайда булды бары караш белән
Аңлашыла торган татулык?
Безнең сөю — сөю түгел хәзер,
Мәҗбүр булган өчен якынлык.

Мин арыдым синнән, син дә мине
«Үзгәртүдән» тукта, сабыр ит!
Безнең тормыш — әйтерсең лә төссез
Һәм күңелсез чиксез лабиринт.

* * *

Иртә иде әле көз булырга,
Июльләрдә йөрәк тавышым,
Күңелемдә әле җәй уртасы,
Ә бит көзгә кереп барышым.

Кагылалар минем яңакларга
Ут-барбарис, миләш бәйләме,
Вакыт урманымда — яфрак түе,
Ә күңелдә — гөлләр бәйрәме.

Ә күңелдә — хисләр тантанасы,
Әйтеп бетергесез хозурлык,
Син бар миндә, шуңа гомер көзем
Барлык язларыма торырлык.

* * *

Югалту артыннан югалту,
Ә ялгыз минутлар ачылыр,
Сиреньнәр куагы өстенә
Тама да тәгәри тамчылар.

Тама да тәгәри... Ничә яз,
Ничә көз тәрәзәм артында.
Шыбырдый шул сирень куагы
Һәр төндә ялгызлык хакында.

Ул мине юатып сүз әйтми,
Ул мине тик өнсез искәртә:
Бу көннәр артыннан, бу еллар,
Гомерләр зыяга үткәнгә.

Ах сирень, син дә бит ялгызсың,
Шыбырда, юат бер тагын да:
Битараф ят белән бер мендәр бүлгәнче,
Шул горур ялгызлык хакында.

## Кыйбла

Элмә күләгәләр күңелемә,
Үткәннәрдә кояш янганга,
Мәхәббәтем кайнар ком чүлендә
Яшел утрау булып калганга.

Киртә корма, көчең җитә алмас,
Сахраларда сәмум җиленә,
Яз булса да синең дәрьяларда
Дулкын какмый күңелем күленә.

Син кагылма минем күңелемә,
Сәҗдә кылсам, кыйблам — чүлдәдер,

Ялгышларым бары үземнеке,
Хөкем итү язык кемгәдер.

Син кагылма минем үткәннәргә,
Үткәнемдә — Кояш, Җидегән,
Тын үзәннән күпме бәндә үткән,
Тик бик азлар күккә үрелгән.

Оҗмахларың миңа кирәк түгел,
Үз гөнаһым үземә җитәрлек.
Үз кыйбламда һаман сөю яна,
Пәйгамбәрләр тәкбир әйтерлек.

## Кырык яшьтә

Пәйгамбәр яры яшендә —
Минем иң пешкән чагым,
Үзем теләп учларыңа
Өзелеп төшкән чагым.

Минем әле шундый чагым —
Ут булып янам кебек,
Кыраудан соң көз башында
Балланган балан кебек.

Минем әле шундый чагым —
Дөньяга алкышым бу,
Үкенечкә калган язның
Күзендә балкышым бу.

Пәйгамбәр яры яшендә —
Хисләрне тыймас чагым,
Кадереңне белеп сөяр,
Сөелеп туймас чагым.

* * *

*С.Есениннан*

Сау бул инде, дускай, хуш, бәхил бул.
Якын дускай җанда китәчәк.
Хушлашуны һәрчак очрашу дип,
Вәгъдә итә безгә киләчәк.

Сау бул инде, дускай, сүзсез генә,
Ачуланма, кашың җыерма, —
Бу дөньяда үлем яңа түгел,
Һәм яшәүдә тынып өермә.

* * *

Аерылуның ачы җиле
Аралардан узды инде,
Күңелләрдә — көзге салкын —
Читләшүнең бозы инде.

Ялкын гына җылытала,
Җылытучы төтен булмас,
Бер киселгән икмәк кире
Бөтен булмас, бөтен булмас.

Йокыларың кисеп таңда
Тәрәздән болыт агылса,
Яки, ятим көчек кебек,
Тезеңә җилләр кагылса,

Юатучың, юк, мин булмам,
Күздән киткән — җаннан купкан.
Кемгә — хәсрәт, кемгә — шатлык,
Уртак хисне упкын упкан.

Урамда май — дөнья гөрли,
Офыкларда яшел ялкын,
Араларда — ачы җилләр,
Күңелләрдә — күзге салкын,

Үз-үземә урын тапмыйм.

## *Кәлтә эзе*

Апрель киче, яшел урман
Индә — синең куллар...
Ай, урау һәм бик бормалы
Булды безнең юллар.

Затлык бүләк — яшма тартма
Өстәлемдә балкый.
Капкачында — көмеш кәлтә
Үзенә урын тапмый.

Алтын таҗын кырын салып,
Ята көмеш кәлтә.
Икебезнең арабызга
Кора көмеш ятьмә.

Ураласың шул ятьмәгә,
Җаның юатасың,
Кабатланмас бу елларны,
Мине югалтасың,
Югалтасың һәм үзеңне
Юкка юатасың.

Апрель киче, утлы тамчы
Үзәкләргә тамды,
Алтын таҗлы көмеш кәлтә
Зәһәрләнеп янды,
Сөюеңнән күңелемдә
Кәлтә эзе калды.

## Ике арада

Тибрәлә болыт түбәмдә,
Уйнамый яшен-камчы
Остаз кебек спас керде,
Тәрәздә — елак тамчы.

Оеп калган кебек дөнья,
Тынган — тыелган җил дә,
Ә күңел күкләргә дәшә,
Тик нидер баса иңгә.

Тыйма мине, күзләремдә
Эзләмә көзге чалым,
Җәй дә, көз дә түгел җанда,
Минем — дивана чагым.

Күңел сизә, зәңгәр күкләр
Тагын бер күкрәр әле,
Соң түгел, җәйләрнең көзгә
Авышкан гына мәле,
Авышкан гына мәле.

## Тальян гармун

Тальян гармун, синең белән
Мин — яшьлек илләрендә,
Иңгә чәчелгән чәчеңнең
Җылысы беләгемдә.

Үткән, үкендергән еллар
Моңнарын өзмим әле,
Яшьлектә калган ярымны
Җырлардан эзлим әле.

Кире кайтмас үткән гомер —
Төш кенә төннәремдә,
Әйтелми калган сөюем
Тальяным телләрендә.

Гомергә сүнми, сүрелми,
Сөюем йөрәгемдә.
Кара толымындай ята
Каешы иңнәремдә.

## Зәңгәр күзле ак эт

Без яшь әле, сөю — бар дөнья,
Зәңгәр күзле көчек болдырда.

Булалмыйча, бахыр, кемгә дә,
Сырпаланды килеп эргәгә.

Терәп тезгә тугры башкаен,
Зәңгәр күзле ап-ак маңгаен.

Ул илгәзәк без дип җан атты,
Икебезне бер тиң яратты.

Кайнар төннәр, дымлы иреннәр,
Су коену төнге Иделдә...

Уртак еллар, дуслар, табыннар,
Анда-санда — чит-ят чалымнар...

Гомер үтә, йөздә — җыерчык,
Көзгедәге чырай — кыерчык —

Шиңгән гөлләр кебек бакчада
(Сатып алып булмый акчага).

Житалмадык бергә «кичүгә»,
Бер сөюне бүлеп икегә.

Сөю үткәч, нәрсә бүлешик?
Миңа — унга, сиңа — сул ишек.

Тик бер әйбер икән уртак бар:
Зәңгәр күзле ак эт — уртак мал.

Кайда итик аны, ни эшлик,
Уртагамы аны бүлешик?

Койрык болгый тугры, ни чара?
Зәңгәр күзле ак эт — бичара.

## Эт гомере

Муртык сөякләрдә — әче сызлау,
Зәңгәр күздә — гүрләр карасы.
Мизгел генә булды бу яшәүләр,
Көчеклек һәм этлек арасы.

Кайчан гына өмет белән җирдә
Кешеләргә койрык болгадым,
Ялтыр сыртны куеп көн нурына,
Хуҗам капка төбен тырнадым.

Җилдән җитез җилеп күпме тапкыр
Куып тоттым җәнлек, киекне.
Этбикәгә үлеп гашыйк булдым,
Ун эт белән азак йөгерде.

Янда мин булганда хуҗа кеше
Урамнардан кыю атлады.
Койрык кысып качып бетте этләр,
Ә кешеләр элде капканы.

Төрле чаклар булды: исерек хуҗа
Мине җәлләп кочып елады,
Ә иртәсен бер дә юкка гына,
Таяк белән кисте, кыйнады.

Эт көне дә булды, кот көне дә:
Бер сыныкка кайчак тилмертте,
Ә шулай да индә көч булганда,
Майлы сөяк күбрәк кимертте.

Гөрли дөнья, бала-чага көлә,
Тешсез бер карт ойый тупсада,
Их, ялыйсы иде майлы шулпа,
Йә бер сөяк кенә булса да...

Соңгы нурлар сүнде эт күзендә,
Тәпиенә ауды башлары...
...Кышлау гөл артыннан
Ак чәчле кыз
Тәрәз ачып сөяк ташлады.

Эт гомере шулай тәмамланды,
Эт гомере шулай башланды.

## Үлем хакында

«...Бик күңелсез булыр мин үлгәч...»

*Һ.Такташ*

Кыш көнендә, юк, үләсем килми,
Юк, теләмим буран япканын,
Салкын карның тәңкә-тәңкә булып
Эремичә биткә ятканын.

Кышлардан соң килә ярсу язлар,
Мин яңадан туам шикелле,

Гөрләвекләр ага, бөре бүртә,
Үлеп буламыни шул көнне!

Ә соң җәйдә — төпсез зәңгәр күкләр,
Бер кошчыкка үзең әйлән дә
Җырлар җырла, нурга коен гына,
Үлем кайгысымы җәйләрдә?!

Күз яшьләрен коя көзге урман,
Ире киткән кебек хатыннан.
Кешеләргә болай да бит моңсу,
Юк, үлмәм мин көзләр артыннан.

Бу дөньяның саждә һәр мизгеле,
Китүләрем моннан икеле.
Үлсәм, үземә дә моңсу булыр,
Мин бөтенләй үлмәм шикелле.

* * *

Өзелде иске моңлы җыр,
Яңасы туа җанда.
Кайдадыр учак ялкыны,
Әйтерсең яңа яра.

Төн тынлыгын тыңлап торам,
Серле моң ишетелә.
Гүя еллар төпкеленнән
Үткәннәр тавыш бирә:

«Кабыздык без яшәешнең
Мәңгелек утын сездә,
Сүндермичә киләчәккә
Илтегез котын сез дә.

Буыннарга ләгънәтләрсез
Бары изгелек калсын.
Тереклек әҗәле түгел,
Яшәеш уты янсын».

Атам-бабам нигезе бу,
Минем дә изге йортым,
Нәнием бишеге монда —
Ышанычым, өметем.

Секундлар ага, минутлар,
Елларым, гомерләрем.

Үземнән соң учагымда
Калырмы күмерләрем?

Башкалар җылына алырлык
Булырмы гомерләрем?!

# Эчтәлек

Һәр юлында — Сөю уты. *Рәдиф Гаташ* . . . . . . . . 5

I

Вакыт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Ташлар җыям . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Минем халкым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Әй гомерләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
«Әйтерсең лә безгә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Көмеш дага . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Тоз һәм шырпы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Танклар китә Чечняга . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Ялгыз кабер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Язгы төш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
«Бөтенләйгә түгел, бер сәгатькә...» . . . . . . . . . 21
Туган җир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
«Тол хатындай моңсу ак болытлар...» . . . . . . . . 23
Моңлы карт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Карт солдат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Гомер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
«Юлсыз җирдән сукмак ярсаң...» . . . . . . . . . . 27
Җәяүле буран . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Алмаз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Метеор монологы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Язылмый калган шигырь турында . . . . . . . . . . 32
Шагыйрь . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Кызыма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
«Йоклый улым — бәләкәчем...» . . . . . . . . . . . . 34
«Табигатьнең серле бу хәтере...» . . . . . . . . . . . 34
«Нуриманым — җантөягем...» . . . . . . . . . . . . . 36
Баланнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Соңгы аваз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Давыл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
«Яшел үлән кебек яшел бәбкә...» . . . . . . . . . . . 40
Хушлашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Йөрәк кылым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Чәчкә көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42

## II


Сагындым сөйгәнемне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
«Болытлар тулышып тора...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Төнге урам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
«Көзге яфрак — ялгыз аккош...» . . . . . . . . . . . . . . . 46
«Хыялларым, омтылышлар...» . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Кем син? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Аяз яңгыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
«Декабрьдә яңгыр явып үтте...» . . . . . . . . . . . . . . 48
«Йөгерә-атлый миннән ераклаштың...» . . . . . . . . . . . 48
«Аерылыштык, арабызга ятты...» . . . . . . . . . . . . . . 49
Үпкәләтмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
«...Китмә, дисең, тик бик азга гына...» . . . . . . . . . . 50
«Яңгырдан каралган йортлар...» . . . . . . . . . . . . . . 51
«Барысын да шаяртуга бордың...» . . . . . . . . . . . . . . 52
Исеңдәме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Кояш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
«Миңа да бит җиңел түгел...» . . . . . . . . . . . . . . . . 54
«Биеклекләргә чакырдым...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Үпкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
«Һәркемнең үзенекедер...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
«Ташулар булып таштым бит...» . . . . . . . . . . . . . . . 56
Язмышлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
«Ул синең ялгышың, диләр...» . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Ничек бармын, шулай ярат . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Кыюсызлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
«Син күкләрдән җиргә төштең инде...» . . . . . . . . . . . 60
Синең белән һәм синсез . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
«Күкләремне телеп яшен үтсә...» . . . . . . . . . . . . . . 62
«Ничә кат очраштык, ничә кат хушлаштык...» . . . . 63
«Учагымда ут сүрелеп бара...» . . . . . . . . . . . . . . . 63
«Кайлардан үтте юлларың...» . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Ялгызың каласың ла... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
«Юк, берни дә безне бәйләмәде...» . . . . . . . . . . . . . 65
«Мәңгелегем!» димә миңа...» . . . . . . . . . . . . . . . . 65
«Төшләреңә керсәм әгәр...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Төш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
«Кайда булды үкенүләр...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
«Ромашкалар, кыңгыраулар иле...» . . . . . . . . . . . . . 68
«Яхшылыкта, яктылыкта...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 69

«Кайгыларны, рәнҗү, үпкәләрне...» . . . . . . . . . 70
«Әй борчыла күңел, әй давыллый...» . . . . . . . . 70
«Йолдызлар берни дә аңламый...» . . . . . . . . . 71
«Тәрәзәгә пәрдә кормыйм мин...» . . . . . . . . . 72
«Әүвәлгеләр искә төшми...» . . . . . . . . . . . 72
Кара кош . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
«Таң алдыннан тагын буран...» . . . . . . . . . . 73
«Еллар аша, юллар аша...» . . . . . . . . . . . 74
«Менә синнән бары шушы калган...» . . . . . . . . 75
«Юк, кайтарып булмый үткәннәрне...» . . . . . . . 76

### III

«Әй дөньяның матур чагы...» . . . . . . . . . . . 78
«Гомеремнең җәй уртасы...» . . . . . . . . . . . 78
«Курайларның сут тутырган мәле...» . . . . . . . . 79
«Табигатьтә инде көз тавышы...» . . . . . . . . . 79
Очкынлана яфраклар . . . . . . . . . . . . . . 80
«Урманнарда алтын туйлар бара...» . . . . . . . . 80
«Акрын гына, ялкау гына...» . . . . . . . . . . . 81
Учак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
«И көзләрнең моңсу сарылыгы...» . . . . . . . . . 82
«Йөгерек җилләр салмакланган сыман...» . . . . . . 83
«Ә кылганнар инде бәс төсендә...» . . . . . . . . 83
«Көз инде, көз, болыннарга...» . . . . . . . . . . 84
«Алтын нурга чумган...» . . . . . . . . . . . . . 84
Яңа ел алдыннан . . . . . . . . . . . . . . . . 85
«Хушлаша көз, китүендә...» . . . . . . . . . . . 86
«Хыянәтче, салкын, аяусыз көз...» . . . . . . . . 86
Серле җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
«Көмеш табанлы чаналар...» . . . . . . . . . . . 88

### IV

«Үз илендә пәйгамбәрләр булмый...» . . . . . . . . 90
Мин хатын-кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Шәмәхә төн . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
«...Күңелемне тагын яз биләде...» . . . . . . . . . 92
Колын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Яңа йорт сала егетләр . . . . . . . . . . . . . 94
Дуска . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Кенәри . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
«Үтмәс, дисәм, үтә бу минутлар...» . . . . . . . . 96

Үзем хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Синең сипкелләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Урман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Алтын балдак . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Өмет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Янәш тәрәзәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
«Олыгайта күзгеләр дә...» . . . . . . . . . . . . 102
Каеннар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Ике гөл үкенече . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Ялгыз тирәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Казан дусларыма . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Ак тынлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Кызыл шомырт . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
«Тәрәзгә маңгай терәп...» . . . . . . . . . . . . 106
«Кайларда йөрдек икән без...» . . . . . . . . . . 106
«Син йоклыйсың, ә мин китәм синнән...» . . . . . . . 107
«Чәчкә кададың чәчемә...» . . . . . . . . . . . . 107
«Әйт миңа сөю сүзләре...» . . . . . . . . . . . . 108
«Якты күңел тәрәзләрем...» . . . . . . . . . . . . 108
Былтыргы көз... . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
«Чәчелмәгән, түгелмәгән әле...» . . . . . . . . . . 109
«Яңа елда ташсын шашкан хисләр...» . . . . . . . . 110
«Килә-китә, яна яңа мизгел...» . . . . . . . . . . 110
Сөйләшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Мизгелләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Сиреньнәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
«Тагын китәм, аерылабыз...» . . . . . . . . . . . 112
Мин арыдым синнән . . . . . . . . . . . . . . . 112
«Иртә иде әле көз булырга...» . . . . . . . . . . 113
«Югалту артыннан югалту...» . . . . . . . . . . . 114
Кыйбла . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Кырык яшьтә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
«Сау бул инде, дускай...» . . . . . . . . . . . . 116
«Аерылуның ачы җиле...» . . . . . . . . . . . . . 116
Кәлтә әзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Ике арада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Тальян гармун . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Зәңгәр күзле ак эт . . . . . . . . . . . . . . . 119
Эт гомере . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Үлем хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Өзелде иске моңлы җыр . . . . . . . . . . . . . 122

Литературно-художественное издание

# Фиолетовая ночь

МУДАРРИСОВА ХАЛИСА САГИТОВНА

Стихи

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Д.Ю.Смыков*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Р.В.Сабирҗанов*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 22.04.2003.
Форматы 70×90 1/32. ВХИ кәгазе. «Korinna» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 4,68+форз. 0,15.
Шартлы буяу-оттиск 5,56. Нәшер-хисап табагы 4,55+форз. 0,26.
Тиражы 2000. Заказ Я-229.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәѐләт унитар
предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.